**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** 08.12.2014 г. Казань **БОЕРЫК** №886-п

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының атмосфера һавасын саклау, шул исәптән атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка матдә ташландыклары өчен түләүне контрольдә тоту өлкәсендә төбәкара дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында**

“Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 26.12.2008 ел, №294-ФЗ Федераль законның 5 статьясы һәм “Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең дәүләт функцияләрен һәм административ регламентларын үтәүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында” 16.05.2011 ел, № 373 Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары нигезендә **боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының атмосфера һавасын саклау, шул исәптән атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка матдә ташландыклары өчен түләүне контрольдә тоту өлкәсендә төбәкара дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын (алга таба – Административ регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 23 гыйнварында №2200 белән теркәлгән “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының атмосфера һавасын саклау, шул исәптән атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка матдә ташландыклары өчен түләүне контрольдә тоту өлкәсендә төбәкара дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында”гы 09.12.2013 ел, №723-п Боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге административ регламентның үтәлешен контрольдә тотуны Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе башлыгы Ф.Ф. Шакировка йөкләргә.

4. Хокукый тәэминат бүлегенә (В.А. Тронин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгында теркәтергә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Р.Х. Низамовка йөкләргә.

Министр А.Г. Сидоров

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый
ресурслар министрлыгының
2014 елның “08” декабрендәге,
№886-п боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАР МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ АТМОСФЕРА ҺАВАСЫН САКЛАУ, ШУЛ ИСӘПТӘН АТМОСФЕРА ҺАВАСЫНА ПЫЧРАТКЫЧ МАТДӘ ҺӘМ БАШКА МАТДӘ ТАШЛАНДЫКЛАРЫ ӨЧЕН ТҮЛӘҮНЕ КОНТРОЛЬДӘ ТОТУ ӨЛКӘСЕНДӘ ТӨБӘКАРА ДӘҮЛӘТ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮНЕҢ АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент), “атмосфера һавасын саклау, шул исәптән атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка матдә ташландыклары өчен түләүне контрольдә тоту өлкәсендә төбәкара дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру” дәүләт функциясен (алга таба – дәүләт функциясе, дәүләт күзәтчелеге) үтәгәндә Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының (алга таба – ТР ЭТРМ) эшләү вакытларын һәм тәртибен билгели.

Атмосфера һавасын саклау өлкәсендәге төбәкара дәүләт күзәтчелеге төбәкара дәүләт экология күзәтчелегенең җыелма өлеше булып тора, аны үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген башкару буенча

дәүләт функциясен үтәүнең Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 09.12.2013, №721-п боерыгы белән расланган административ регламенты (алга таба – Төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча административ регламент) белән билгеләнгән.

1.2. Дәүләт функциясен үтәүче булып ТР ЭТРМ тора.

Дәүләт функциясен турыдан-туры үтәүчеләр булып ТР ЭТРМ дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе һәм ТР ЭТРМ территориаль идарәләре санала.

Дәүләт функциясе турыдан-туры ТР ЭТРМ вәкаләтле затлары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 21 сентябрендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазифаи затлары исемлеген раслау турында”гы №784 карары нигезендә билгеләнгән Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча дәүләт инспекторлары (алга таба – вазифаи затлар) тарафыннан башкарыла.

Дәүләт функциясен үтәгәндә вазифаи затлар прокуратура органнары, эксперт оешмалары, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр белән үзара элемтәдә тора.

1.3. Дәүләт функциясе түбәндәгеләргә нигезләнеп үтәлә:

Россия Федерациясе Конституциясе (“Российская газета” №237, 1993 елның 25 декабре, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2001 елның 30 декабрендә кабул ителгән №195-ФЗ Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексы (алга таба – РФ КоАП) (“Россия Федерациясе законнар җыелмасы”, 07.01.2002 ел, №1 (1 ө.), 1 ст.) кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Атмосфера һавасын саклау турында” 04.05.1999 ел, №96-ФЗ Федераль закон (алга таба – 04.05.1999 ел, №96-ФЗ) (“Россия Федерациясе законнар

җыелмасы", 03.05.1999 ел, №18, 2222 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" 10.01.2002 ел, №7-ФЗ Федераль закон, (алга таба – 10.01.2002 ел, №7-ФЗ) ("Российская газета", №6, 2002 елның 12 гыйнвары, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 02.05.2006 ел, №59-ФЗ Федераль закон, ("Россия Федерациясенең законнар җыелмасы", 08.05.2006 ел, №19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында" 26.12.2008 ел, №294-ФЗ Федераль закон, (алга таба – №294-ФЗ) ("Россия Федерациясе законнар җыелмасы", 29.12.2008 ел, №52 (1 ө.), 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Атмосфера һавасына зарарлы йогынтыларны һәм аларның чыганакларын дәүләт исәбенә алу турында нигезләмә раслау хакында" 21.04.2000 ел, №373 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, ("РФ законнар җыелмасы", 01.05.2000, № 18, 1987 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Атмосфера һавасында зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларының һәм аңа физик йогынтыларның нормативлары турында" 02.03.2000 ел, №183 карары ("РФ законнар җыелмасы", 13.03.2000 ел, № 11, 1180 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 июнендә кабул ителгән "Дәүләт контроле (күзәтчелеге) мәсьәләләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын гамәлдән чыккан дип тану турында" №476 карары белән расланган Атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмә ("Россия Федерациясе законнар җыелмасы", 17.06.2013 ел, №24, 2999 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

Россия Икътисади үсеш министрлыгының “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру турында” 30.04.2009 ел, №141 боерыгы (алга таба – Россия Икътисади үсеш министрлыгының №141 боерыгы) (“Российская газета”, № 85, 14.05.2009 ел, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

РФ Табигать министрлыгының “Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыклары чыганаклары булган юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне, һәм шулай ук атмосфера һавасындагы зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыклары күләмен һәм составын дәүләт исәбенә алу тәртибен раслау турында” 26.10.2011 ел, №863 боерыгы (“Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене”, №14, 02.04.2012);

РФ Табигать министрлыгының “Дәүләт исәбенә алынырга һәм нормаланырга тиешле, атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыклары чыганакларын ачыклау тәртибе турында һәм Дәүләт исәбенә алынырга һәм нормаланырга тиешле зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең исемлеге турында” 31.12.2010 ел, №579 боерыгы (“Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене”, №10, 07.03.2011);

ГОСТ 17.2.3.02-78 “Табигатьне саклау. Атмосфера. Сәнәгать предприятиеләренә рөхсәт ителүче зарарлы матдә ташландыкларын билгеләү кагыйдәләре” (М.: Издательство стандартов, 1984);

Атмосфера һавасына булган пычраткыч матдә ташландыкларын хисаплау, нормалау һәм контрольдә тоту буенча методик ярдәмлек (тулыландырылган һәм эшкәртелгән), “НИИ Атмосфера” ААҖ, С-Пб. ш., 2012 ел;

Атмосфера һавасына предприятиеләрдән чыгучы ташландыклардагы зарарлы матдә концентратларын хисаплау методикасы. СССРның

гидрометеорология һәм табигый тирәлекне контрольдә тоту буенча дәүләт комитеты тарафыннан расланган ОНД-86, 04.08.1986, № 192;

Методик күрсәтмәләр. Начар метеорология шартларында ташландыкларны җайга салу. РД 52.04.52-85 (СССР Госкомгидромет тарафыннан 1986 елның 1 декабрендә расланган);

Атмосферадагы зарарлы матдә ташландыкларын инвентаризацияләү буенча күрсәтмә (СССР Госкомгидромет тарафыннан расл.). – Л., О-во “Звание” РСФСР. Ленинград оешмасы. ЛДНТП, 1991;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында начар һава шартлары чорларында атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын җайга салу эшләрен оештыру турында” 22.05.2012 ел, №407 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы”, 01.06.2012 ел, № 41, 1325 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген башкаручы вазифаи затлары исемлеген раслау турында” 21.09.2011 ел, №784 карары (алга таба – 21.09.2011 ел, №784 ТР МК Карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы”, 26.10.2011, №40, 2038 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре” турында 06.07.2005 ел, № 325 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре җыентыгы һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары”, 27.07.2005, № 28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының “Газчистарткыч җайланмаларны куллану буенча гомуми таләпләр”не раслау турында” 02.08.2004 ел, №761 боерыгы (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы”, 19.01.2005, № 3, 0059 ст.);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының “Төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының административ регламентын раслау турында” 09.12. 2013 ел, №721-п боерыгы (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы хокукый мәгълүматының рәсми сайты, http://pravo.tatarstan.ru, 31.01.2014, “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы”, 06.05.2014, №33-34, 1040 ст.).

1.4. Дәүләт күзәтчелеге оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренең нинди булуына карамастан, төбәкара дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектларында гамәлгә ашырыла.

Дәүләт күзәтчелегенең предметы юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең һәм гражданнарның Россия Федерациясенең халыкара килешүләре, 04.05.1999, №96-ФЗ “Атмосфера һавасын саклау турында”, 10.01.2002, №7-ФЗ “Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” Федераль законнар, башка федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителүче Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының атмосфера һавасын саклау өлкәсендәге, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнары һәм норматив-хокукый актлары нигезендә билгеләнгән таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәвеннән гыйбарәт.

1.5. Дәүләт күзәтчелеген башкарганда вазифаи затларның хокуклары һәм бурычлары.

1.5.1. Тикшерүне үткәрергә вәкаләтле ТР ЭТРМ вазифаи затлары Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән һәм гражданнардан керүче дәлилле язма гаризалар нигезендә тикшерү барышында кирәкле мәгълүматны һәм документларны соратырга һәм алырга;

2) хезмәт таныклыгын һәм министрның (министр урынбасарының) тикшерүне билгеләү турындагы боерыгы (әмернамәсе) күчермәсен күрсәткән очракта, бернинди каршылыксыз, хуҗалык яки башка эшчәнлекне гамәлгә ашырганда юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан файдаланылучы территорияләрне, биналарны, бүлмәләрне, корылмаларны, шул исәптән чистарткыч корылмаларны карарга һәм тикшерергә, башка зарарсызландыручы җайланмаларны, контроль чараларын, техник һәм транспорт чараларын, җайланмаларны һәм материалларны тикшерергә, шулай ук күзәтчелек буенча зарури тикшеренүләрне, сынауларны, үлчәм алуларны, эзләнүләрне, экспертизаларны һәм башка чараларны үткәрергә;

3) үткәреләчәк тикшерүне №294-ФЗ Федераль закон нигезендә прокуратура органнары белән килештерү турында гариза юлларга;

4) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм гражданнарга ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында, үсемлекләргә, хайваннарга, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләти һәм муниципаль милеккә зыянны булдырмауны, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны булдырмауны тәэмин итү буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр бирергә;

5) мәҗбүри таләпләрне бозуларга бәйле административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә, күрсәтелгән административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерергә һәм мондый бозуларны бетерү буенча чаралар күрергә;

6) җинаять билгеләре буенча җинаять эшләрен ачу мәсьәләсен хәл итү өчен вәкаләтле органнарга әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә законнарны бозуга бәйле материаллар җибәрергә;

7) Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә әйләнә-тирә мохиткә һәм аның кисәкләренә кагылышлы мәҗбүри таләпләрне бозу нәтиҗәсендә салынган зыянны каплау турында шикаятьләр бирергә;

8) аларга карата тикшерү үткәрелүче юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән граждан-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелүче затларның аффилир затлары булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын тикшерүне үткәрүгә җәлеп итәргә.

1.5.2. Тикшерүне үткәрүгә вәкаләтле ТР ЭТРМ вазифаи затлары тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләрне тиешле:

1) Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм бетерү буенча бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәргә;

2) Россия Федерациясе законнарын үтәргә, тикшерелүче юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокукларын һәм законлы ихтыяҗларын үтәргә;

3) тикшерүне министрның (министр урынбасарының) аны үткәрүне билгеләү турындагы әмернамәсе нигезендә үткәрергә;

4) тикшерүне бары тик хезмәт вазифаларын башкарганда гына, урынга чыгып тикшерүне бары тик хезмәт таныклыкларын, министр (министр урынбасары) әмернамәсенең күчермәсен һәм, №294-ФЗ Федераль законның 10 статьясының 5 өлешендә каралган очракта, тикшерүне үткәрүне килештерү турындагы документ күчермәсен күрсәткән очракта гына үткәрергә;

5) юридик затның җитәкчесенә, башка вазифаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерүне үткәрүдә катнашуына каршы килмәскә һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

6) тикшерүне үткәрүдә катнашучы юридик зат җитәкчесенә, башка

вазифаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагылышлы мәгълүматларны һәм документларны бирергә;

7) юридик зат җитәкчесен, башка вазифаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) ачыкланган бозу очраклары буенча кабул ителүче чараларны билгеләгәндә, әлеге чараларның бозуларның катлаулылыгына, аларның кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре), дәүләт иминлеге өчен, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу буенча потенциаль куркынычлылыгына туры килүен исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы ихтыяҗларын нигезсез чикләүгә юл куймаска;

9) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр шикаять җиткергәндә үз эшчәнлекләренең Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә нигезләнгән булуын дәлилләргә;

10) тикшерүләрне үткәрүнең №294-ФЗ Федераль законда каралган вакытларын үтәргә;

11) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән Россия Федерациясе законнарында аларны тапшыру каралмаган документларны һәм башка белешмәләрне таләп итмәскә;

12) юридик затның җитәкчесе, башка вәкаләтле заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле гозере буенча урынга чыгып тикшерү үткәрер алдыннан, аларны әлеге Регламентның тикшерүне үткәрүгә нигез булган нигезләмәләре белән таныштырырга;

13) үткәрелгән тикшерү турында исәп журналына язу теркәргә;

1.5.3. Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча дәүләт инспекторлары булган ТР ЭТРМ вазифаи затлары түбәндәгеләргә хокуклы

түгел:

1) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерергә, әгәр дә ул таләпләр ТР ЭТРМ исеменнән гамәл кылучы әлеге вазифаи затларның вәкаләтләренә кермәсә;

2) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян салу, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә зарар китерү, һәм шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу нигезендә уздырылган тикшерү очрагыннан гайре, тикшерүне үткәргән вакытта юридик затның җитәкчесе, башка вазифаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, аңа карата урынга чыгып, планлы яисә планнан тыш тикшерү үткәрергә;

3) тикшерү объекты булмаган яисә тикшерү предметына карамаган документларны, мәгълүматларны, әйләнә-тирә мохит объектларының һәм җитештерү өлкәсе объектларының продукциясе үрнәкләрен, тикшерү пробаларын таләп итәргә, һәм шулай ук мондый документларның төп нөсхәләрен алырга;

4) аларга карата тикшеренүләр, сынаулар үткәрү, үлчәмнәр алу өчен продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларының һәм җитештерү объектларының тикшерү пробаларын, әлеге үрнәкләрне, пробаларны алу буенча билгеләнгән рәвештә беркетмәләр төземичә һәм үрнәкләрне, пробаларны алу һәм аларга карата тикшеренүләр, сынаулар үткәрү, үлчәмнәрен алу методларының илкүләм стандартларында, кагыйдәләрендә, техник регламентларында яисә аларны гамәлгә ашыру көненә гамәлдә булган башка норматив-техник документларда һәм тикшеренүләрнең, сынауларның, үлчәм алу кагыйдәләрендә һәм методларында билгеләнгән нормаларны артып киткән күләмдә алырга;

5) Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан гайре, тикшерү барышында алынган һәм дәүләти, коммерциячел, хезмәт яисә закон

тарафыннан саклануучы башка серне тәшкил итүче мәгълүматларны таратырга;

6) тикшерү үткәрүнең билгеләнгән вакытларын озынайтырга;

7) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә алар хисабыннан контроль буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр бирергә.

1.6. Аларга карата дәүләт күзәтчелеге буенча чаралар үткәрелүче затларның хокуклары һәм бурычлары.

1.6.1. Тикшерүне үткәргән вакытта юридик затның җитәкчесе, башка вазифаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле түбәндәгеләргә хокуклы:

1) үткәрелүче тикшерүдә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләргә карата аңлатмалар бирергә;

2) ТР ЭТРМ, аның вазифаи затларыннан тикшерү предметына карый торган һәм аны бирү №294-ФЗ Федераль законда каралган мәгълүматны алырга;

3) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актындагы тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы, алар белән, шулай ук ТР ЭТРМ вазифаи затларының эше белән килешүен яисә килешмәвен күрсәтергә;

4) тикшерүне үткәргәндә ТР ЭТРМ вазифаи затларының юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокукларын бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә шикаять бирергә;

5) Россия Федерациясе Президенты каршында эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Вәкаләтле Вәкилне яисә Татарстан Республикасы Президенты каршында эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Вәкаләтле Вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.

1.6.2. Юридик затның җитәкчесе, башка вазифаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле тикшерүне үткәргән вакытта түбәндәгеләрне бурычлы:

1) тикшерүне үткәрүгә вәкаләтле вазифаи затлар соратып алган

документларны һәм материалларны тапшырырга, һәм шулай ук тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча телдән яисә язмача аңлатамалар бирергә;

2) урынга чыгып тикшерү үткәрүче вазифаи затларга һәм урынга чыгып үткәрелүче тикшерүдә катнашучы экспертларга, эксперт оешмалары вәкилләренә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеген гамәлгә ашыруда файдаланылучы территориясенә, биналарына, төзелмәләренә, корылмаларына, бүлмәләренә, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан файдаланылучы җайланмаларга, мондый төр объектларга, транспорт чараларына һәм алар тарафыннан ташылучы йөкләргә үтеп керү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

3) катнашырга яисә мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыруга һәм үткәрүгә җаваплы булган вазифаи затларга катнашу мөмкинлеген тудырырга.

1.7. Дәүләт функциясен үтәүнең нәтиҗәләрен тасвирлау.

Планлы, планнан тыш тикшерү нәтиҗәләре буенча ТР ЭТРМ вазифаи затлары тарафыннан түбәндәге документлар төзелә:

Төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруда дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентының 1 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә, юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең атмосфера һавасын саклау өлкәсендәге законнарны үтәвен, һәм шулай ук атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка матдә ташландыклары өчен түләвенең билгеләнгән вакытларда башкарылуын тикшерү акты;

әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә, ТР ЭТРМ компетенциясе кысаларында (бозу очрагы ачыкланганда), РФ КоАП каралган административ хокук бозу турында беркетмә;

әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә, атмосфера һавасын саклау өлкәсендәге законнарны, шул исәптән атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка матдә ташландыклары өчен түләү

буенча билгеләнгән вакытларны бозуларны (бозу очрагы ачыкланганда) бетерү турында күрсәтмә.

ТР ЭТРМ вазифаи затлары тарафыннан урынга чыгып үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында язу теркәлә.

Гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан (алга таба – мөрәҗәгать итүче) ТР ЭТРМ кергән мәгълүматлар дәүләт функциясен үтәү өчен нигез булган очракта, мөрәҗәгать итүчегә №59-ФЗ Федераль законда каралган тәртиптә дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәләре буенча җавап җибәрелә.

Тикшерүне үткәрү барышында мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланганда, ТР ЭТРМ вазифаи затлары, Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләре кысаларында, ачыкланган бозуларны бетерүне, аларны кисәтүне, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыянны, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә мөмкин булган зыянны булдырмый калуны, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтүне контрольдә тоту буенча чаралар; һәм шулай ук ачыкланган хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә.

Күзәтчелек чараларының нәтиҗәләре буенча затның гамәлләрендә (гамәл кылмауларында) административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда, гаепле затка карата РФ КоАП каралган тәртиптә административ эш кузгатыла.

Әгәр тикшерүне үткәргәндә тикшерелүче зат эшчәнлегенең гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян салуы, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә зарар, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр

китереп чыгаруда турыдан-туры куркыныч янаганлыгы ачыкланса яисә мондый зыян салынса, ТР ЭТРМ кичекмәстән, затның эшчәнлеген РФ КоАП каралган тәртиптә вакытлыча туктатып торуга кадәр, зыян салынуны булдырмый калу яисә аны бетерү буенча, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә куркыныч тудыручы продукциянең кайтавазын бетерү, әйләнештән алу буенча чаралар күрә һәм гражданнарга, шулай ук  башка юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә үтемле булган теләсә нинди юл белән зыян салыну куркынычы барлыгы һәм аны бетерү ысуллары турында мәгълүмат җиткерә.

Күзәтчелек чараларын үткәргән вакытта җинаять билгеләре ачыкланганда, җинаять эшләрен кузгатуны хәл итү өчен атмосфера һавасын саклау өлкәсендәге законнарны бозуга бәйле материалларны вәкаләтле органнарга җибәрү мәсьәләсе хәл ителә.

## 2. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

2.1. Дәүләт функциясен үтәү турында мәгълүмат җиткерү тәртибе.

2.1.1. Әлеге Регламент “Интернет” челтәрендә ТР ЭТРМ рәсми сайтында: www.eco.tatar.ru  урнаштырыла.

2.1.2. ТР ЭТРМ урнашу урыны: 420049, Татарстан Республикасы, Казан ш., Павлюхин ур.,  75 й..

ТР ЭТРМ белешмә телефоннары: 267-68-01, 267-68-70.

Мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен электрон адрес: http://eco.tatar.ru/.

Дәүләт функциясен үтәүче ТР ЭТРМ структур бүлекчәләренең урнашу урыннары турындагы мәгълүмат 2.1 таблицада күрсәтелгән.

**2.1 таблица**. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының дәүләт функциясен үтәүче структур бүлекчәләре турында мәгълүматлар.

| Территориаль орган | Адресы | Хезмәт күрсәтелүче территорияләр | Телефон |
|---|---|---|---|
| Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе | 420049, Казан ш., Павлюхин ур., 75 й. | Татарстан Республикасы | 267-68-67<br>264-34-89 |
| Үзәк территориаль идарә | 420049, Казан ш., Павлюхин ур., 75 й. | Казан ш.<br>Биектау муниципаль районы (алга таба – МР),<br>Лаеш МР<br>Питрәч МР<br>Югары Ослан МР<br>Балык Бистәсе МР<br>Саба МР<br>Теләче МР<br>Яшел Үзән МР | 267-68-33 |
| Төньяк территориаль идарә | 422000, ш.т.п. Арча ш., Интернационал ур., 41 й. | Арча ш.,<br>Әтнә МР<br>Арча МР<br>Балтач МР<br>Кукмара МР | (84366)<br>3-21-61 |
| Идел арты территориаль идарәсе | 422430, Буа ш., Р.Люксембург ур, 159/1 | Буа ш.,<br>Буа МР<br>Чүпрәле МР<br>Апас МР<br>Кайбыч МР<br>Кама Тамагы МР<br>Тәтеш МР | (84374)<br>3-11-02<br>3-34-46 |
| Идел-Кама территориаль идарәсе | 422980, Чистай ш., Фрунзе ур., 97а й. | Чистай ш.,<br>Аксубай МР<br>Алексеевск МР<br>Әлки МР<br>Спас МР<br>Чистай МР<br>Яңа Чишмә МР | (84342)<br>5-35-19<br>5-03-68 |
| Кама арты территориаль идарәсе | 423552, Түбән Кама районы, Кызыл Кизләү п., Яр буе ур, 7 й. | Түбән Кама ш.,<br>Түбән Кама МР<br>Зәй МР<br>Сарман МР | (88555)<br>45-66-56<br>43-90-70 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Кама буе территориаль идарәсе | 423838, Чаллы ш., Җиңүгә 40 ел ур., 64 й. | Чаллы ш., Әгерҗе МР Менделеевск МР Минзәлә МР, Тукай МР Мамадыш МР Алабуга МР Актаныш МР | (8-8552) 59-36-39 59-50-46 |
| Ык буе территориаль идарәсе | 423330, Азнакай ш., Шоссейная ур., 6 й. | Азнакай МР, Баулы МР Мөслим МР Ютазы МР | (8-85572) 2-39-86 (8-85592) 51-5-38 |
| Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарә | 423450, Әлмәт ш., Әминов ур., 9а й. | Әлмәт ш., Бөгелмә МР Лениногорск МР Нурлат МР Чирмешән МР | (8-8553) 33-03-25 33-03-27 |

2.1.3. Дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләренә бәйле документларны һәм мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен ТР ЭТРМ почта адресы: 420049, Казан ш., Павлюхин ур., 75 й.

2.1.4. ТР ЭТРМ (ТР ЭТРМ ҮТИ дә кертеп) эш тәртибе:

Дүшәмбе – пәнҗешәмбе: 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр.

Җомга: 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр.

Төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

ТР ЭТРМ территориаль идарәләренең эш тәртибе:

Дүшәмбе – пәнҗешәмбе: 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр.

Җомга: 8.00 сәгатьтән 15.45 сәгатькә кадәр.

Төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

2.1.5. ТР ЭТРМ, ТР ЭТРМ дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясенең һәм ТР ЭТРМ территориаль идарәләренең урнашу урыны, телефоннары һәм эш тәртибе турында мәгълүматлар http://eco.tatar.ru/ Интернет-сайтында һәм ТР ЭТРМ фойесында, шулай ук дәүләт функциясен үтәүче ТР ЭТРМ территориаль идарәләренең коридорларында, холларында, фойеларында

урнаштырылган мәгълүмати элмә такталарда бар. Әлеге мәгълүматны шулай ук түбәндәгечә дә алырга була:

телефоннар буенча: министрның кабул итү бүлмәсе – 267-68-01;

Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе – 267-68-67.

Әлеге Регламент турындагы белешмәләр Татарстан Республикасында дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләре үтәлүнең Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылган Бердәм административ регламентлары реестрына кертелә – http://mert.tatarsta№.ru.

Дәүләт функциясен үтәү тәртибе турында мәгълүмат дәүләт күзәтчелеген башкаручы вәкаләтле затлар тарафыннан түбәндәгечә бирелә:

– турыдан-туры шәхси кабул итү кысаларында;

– язмача рәвештә (почта аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге Регламентның 2.1.3 пунктында күрсәтелгән реквизитлар буенча);

– eco@tatar.ru электрон почтасы аша;

– “Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы” республика дәүләт мәгълүмат системасы аша (http://uslugi.tatar.ru) (алга таба – Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы).

Дәүләт функциясен үтәү тәртибе турындагы мәгълүмат ТР ЭТРМ рәсми сайтында, ТР ЭТРМ һәм аның дәүләт функциясен үтәүче территориаль идарәләренең гражданнарны кабул итү биналарындагы элмә такталарда урнаштырыла һәм яңартылып тора (әлеге Регламентка кертелгән үзгәрешләргә карап).

2.1.6. Халык алдында телдән мәгълүмат җиткерү массакүләм мәгълүмат чаралары – радио, телевидениене җәлеп итеп башкарыла. Радио һәм телевидение буенча мәгълүмат җиткерүгә җаваплы белгечләрнең чыгышлары министр белән килештерелә.

2.2. Юридик затлардан һәм шәхси эшмәкәрләрдән дәүләт күзәтчелеге буенча чаралар үткәргән өчен түләү алынуга юл куймау.

2.2.1. Дәүләт күзәтчелеге буенча чаралар үткәргән өчен, шул исәптән тикшерү үткәрүгә экспертларны һәм эксперт оешмаларын җәлеп иткәндә – аларның хезмәтләре өчен юридик затлардан һәм шәхси эшмәкәрләрдән түләү алынмый.

2.3. Дәүләт функциясен үтәү вакыты.

2.3.1. Документларны (документар (планлы яисә планнан тыш), шулай ук урынга чыгып (планлы һәм планнан тыш) тикшерү вакыты 20 эш көненнән артып китә алмый.

Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата планлы рәвештә үткәрелүче урынга чыгып тикшерүләрнең вакыты бер ел дәвамында кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артып китә алмый.

Урынга чыгып планлы тикшерү үткәрүче ТР ЭТРМ вазифаи затларының нигезле тәкъдимнәре буенча, катлаулы һәм (яисә) озак вакытлы тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм эзләнүләр үткәрелергә тиешле искәрмәле очракларда, урынга чыгып үткәрелүче планлы тикшерүнең вакыты министр тарафыннан егерме эш көненнән дә артмаган, кече предприятиеләргә, микропредприятиеләргә карата унбиш сәгатьтән дә артмаган вакытка озынайтылырга мөмкин.

Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затка карата (документар, урынга чыгып) тикшерү үткәрү вакыты юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур бүлекчәсе өчен аерым билгеләнә, шул ук вакытта тикшерү үткәрүнең гомуми вакыты алтмыш эш көненнән артып китмәскә тиеш.

2.4. Тикшерү үткәрү өчен нигезләр

2.4.1. Планлы тикшерүләр ТР ЭТРМ тарафыннан ел саен төзелүче тикшерүләр планы нигезендә үткәрелә.

Планлы тикшерүләр үткәрелгән елдан соң килүче елның 1 сентябренә кадәрге вакытка ТР ЭТРМ прокуратура органнарына планлы тикшерүләрне

үткәрүнең еллык планнарының (алга таба – План) проектларын юллый.

Планлы тикшерүне Планга кертү өчен түбәндәгеләр буенча өч елның үтеп китүе нигез булып тора:

1) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең дәүләт теркәвенә алынган көненнән соң;

2) юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата үткәрелгән соңгы планлы тикшерүнең тәмамланган көненнән соң;

3) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең тиешле өлкәдә Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимияте органына эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында тапшырылган белдерүнамәсе нигезендә эшмәкәрлек эшчәнлеге башланган көннән соң, күрсәтелгән белдерүнамәне тапшыру таләп ителүче эшләрне башкарган яисә хезмәтләрне күрсәткән очракта.

Министрның (министр урынбасарының) юридик затны, шәхси эшмәкәрне тикшерү турындагы әмернамәсе Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентының 4 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә формалаштырыла.

2.4.2. Планнан тыш тикшерүләрне үткәрүгә түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) ачыкланган мәҗбүри таләп бозуларны бетерү турында элегрәк бирелгән күрсәтмәнең юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан үтәлү вакыты тәмамлану;

2) түбәндәгеләр хакында гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан ТР ЭТРМ мәгълүматлар керү:

а) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян салыну, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының

мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә зарар килү куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы барлыкка килү;

б) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян салыну, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә зарар килү, һәм шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу;

в) кулланучыларның хокуклары бозылу (хокуклары бозылучы гражданнардан мөрәҗәгатьләр кабул ителгәндә).

3) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре нигезендә һәм прокурорның, прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешен күзәтү кысаларында, планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы таләбе нигезендә министр тарафыннан чыгарылган боерык (әмернамә).

ТР ЭТРМ мөрәҗәгать иткән затны ачыкларга мөмкинлек бирмәүче мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук алда санап үтелгән очраклар буенча белешмәләргә ия булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез була алмый.

Юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне ТР ЭТРМ тарафыннан урынга чыгып планнан тыш тикшерү әлеге пунктның 2 нче пунктчасындагы “а” һәм “б” пункт өлешләрендә күрсәтелгән нигезләр буенча, мондый юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органнары белән килештерелгәннән соң башкарыла.

Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрүне ТР ЭТРМның прокуратура органнары белән килештерүе турында гариза РФ Икътисади үсеш министрлыгының 30.04.2009 ел, №141 боерыгы белән расланган типик үрнәге нигезендә рәсмиләштерелә.

2.5. Дәүләт күзәтчелеген үткәрүне турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазифаи затлар.

Төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген, шул исәптән атмосфера һавасын саклау өлкәсендә төбәкара дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы ТР ЭТРМ вазифаи затларының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 01.09.2011 ел, №784 карары белән билгеләнгән исемлеге 2.2 таблицада күрсәтелгән.

**2.2. таблица**. Төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген, шул исәптән атмосфера һавасын саклау өлкәсендә төбәкара дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы ТР ЭТРМ вазифаи затлары исемлеге

| ТР ЭТРМда вазифаи зат вазифасының исеме | Инспектор вазифасы аталышы |
|---|---|
| Министр урынбасары (дәүләт экология күзәтчелеге мәсьәләләрен күзәтүче) | Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча баш дәүләт инспекторы, Татарстан Республикасының җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, рациональ файдалану һәм саклауны күзәтү буенча баш дәүләт инспекторы, Татарстан Республикасының су объектларын файдалануны һәм саклауны күзәтү буенча баш дәүләт инспекторы |
| ТР ЭТРМ дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе башлыгы; ТР ЭТРМ территориаль идарәләре башлыклары | Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча баш дәүләт инспекторы урынбасарлары, Татарстан Республикасының җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, рациональ файдалану һәм саклауны күзәтү буенча баш дәүләт инспекторы урынбасарлары, Татарстан Республикасының су объектларын файдалануны һәм саклауны күзәтү буенча баш дәүләт инспекторы урынбасарлары |
| ТР ЭТРМ дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе башлыгы урынбасарлары, ТР ЭТРМ территориаль идарәләре башлыклары урынбасарлары | Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча өлкән дәүләт инспекторлары, Татарстан Республикасының җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, рациональ файдалану һәм саклауны күзәтү буенча өлкән дәүләт инспекторлары, Татарстан Республикасының су объектларын файдалануны һәм саклауны күзәтү буенча өлкән дәүләт инспекторлары |

| | |
|---|---|
| Территориаль идарәләрнең махсуслашкан инспекцияләре башлыклары, территориаль идарәләрнең махсуслашкан инспекцияләре башлыклары урынбасарлары; территориаль идарәләрнең махсуслашкан инспекцияләре бүлекләре башлыклары; территориаль идарәләрнең махсуслашкан инспекцияләре бүлекләренең баш белгечләре; территориаль идарәләрнең махсуслашкан инспекцияләре бүлекләренең әйдәп баручы белгечләре; территориаль идарәләрнең махсуслашкан инспекцияләре бүлекләренең 1 нче, 2 нче категорияле белгечләре; территориаль идарәләрнең 2 нче, 3 нче разрядлы өлкән белгечләре; территориаль идарәләрнең 2 нче, 3 нче разрядлы белгечләре; Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясенең 2 нче, 3 нче разрядлы өлкән белгечләре, баш белгечләре, әйдәп баручы белгечләре; Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясенең 1 нче категорияле белгечләре | Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча дәүләт инспекторлары, Татарстан Республикасының җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, рациональ файдалану һәм саклауны күзәтү буенча дәүләт инспекторлары, Татарстан Республикасының су объектларын файдалануны һәм саклауны күзәтү буенча дәүләт инспекторлары |

2.6. № 294-ФЗ Федераль законны бозу буенча юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең җаваплылыгы.

№294-ФЗ Федераль закон бозылуга юл куйган, тикшерүләрне үткәрүгә нигезсез каршы төшкән, үткәрелүче тикшерүләрдән качып йөргән һәм (яисә) мәҗбүри таләпләр буенча ачыкланган бозуларны бетерү турындагы ТР ЭТРМ күрсәтмәләрен билгеләнгән вакытка үтәмәгән юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазифаи затлары яисә юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылы була.

2.7. Тикшерүне үткәргәндә ТР ЭТРМ, аның вазифаи затларының җаваплылыгы.

ТР ЭТРМ, аның вазифаи затлары тиешле функцияләрне, хезмәт вазифаларын җиренә җиткереп үтәмәгәндә, тикшерүне үткәргән вакытта хокуксыз гамәлләр башкарганда (гамәл кылмаганда) Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазифаи затларга карата күрелгән чаралар турында, мондый чаралар күрелү көненнән алып ун көн дәвамында, хокуклары һәм (яки) законлы ихтыяҗлары бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә ТР ЭТРМ язмача рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

## 3. Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата куелучы мәҗбүри таләпләр

Дәүләт күзәтчелеген үткәргәндә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә карата куелучы, аларның үтәлеше контрольдә тотылучы мәҗбүри таләпләрнең, аларны билгеләүче норматив-хокукый актларның, тикшерү барышында юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан күрсәтелергә тиешле документлар исемлеге 2 нче таблицада күрсәтелгән.

**2 нче таблица**. Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата куелучы мәҗбүри таләпләр исемлеге

| **Контрольдә тотылучы объектлар** | **Тикшерелүче таләп** | **Таләпләрне билгеләүче норматив документ** | **Тикшерү барышында юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан күрсәтелүче документлар** |
|---|---|---|---|
| Атмосфера һавасына пычраткыч матдә ташландыкларының стационар чыганаклары булган хуҗалык итүче субъектлар | 1. Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларына һәм аңа зарарлы физик йогынтыларга Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан бирелгән рөхсәтнең булуы | “Атмосфера һавасын саклау турында” 04.05.1999, №96-ФЗ Федераль законның 14 статьясының 1 пункты (алга таба – 04.05.1999, № 96-ФЗ) | Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларына һәм аңа зарарлы физик йогынтыларга Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан бирелгән рөхсәт |
| | 2. Рөхсәтләрдә каралган шартларны үтәү | 04.05.1999, № 96-ФЗның 14 статьясы; 02.03.2000, №183 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Атмосфера һавасындагы зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларының һәм аңа зарарлы физик йогынтыларның нормативлары турында нигезләмәнең 9 пункты; | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларына һәм аңа зарарлы физик йогынтыларга бирелгән рөхсәт;<br>рөхсәтләрдә каралган шартларның үтәлешен раслаучы документлар |
| | 3. Атмосфера һавасын | 04.05.1999, №96-ФЗның 25, 30 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | саклау стандартларын, нормативларын, кагыйдәләрен һәм атмосфера һавасын саклау буенча башка, шул исәптән атмосфера һавасын саклау буенча җитештерү контроле таләпләрен үтәү, һәм шулай ук атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларына карата билгеләнгән һәм вакытлыча килештерелгән ташландыкларның нормативларын, атмосфера һавасына зарарлы физик йогынтыларның рөхсәт ителгән чик нормативларын һәм атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларына һәм аңа зарарлы физик йогынтыларга карата | статьялары; РФ Баш дәүләт санитария табибының 17.05.2001, №14 “Санитария кагыйдәләрен гамәлгә кертү турында”гы боерыгы белән расланган “Торак урыннардагы атмосфера һавасының сыйфатын тәэмин итүгә карата гигиена таләпләре”, СанПиН 2,2,6 1032-01 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | рөхсәтләрдә билгеләнгән башка таләпләрне, шартларны үтәү, | | |
| | шул исәптән законнарда түбәндәгеләрнең тәэмин ителешенә бәйле таләпләрне үтәү: | | |
| | – зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын, ташландык чыганакларының турыдан-туры үзендә һәм контрольдә тотылучы нокталарында (постларында) зарарлы физик йогынтыларны контрольдә тоту; | Атмосфера һавасына пычраткыч матдә ташландыкларын хисаплау, нормалаштыру һәм контрольдә тоту буенча методик кулланма (тулыландырылган һәм эшкәртелгән), "НИИ Атмосфера" ААЖ, С-Пб ш., 2012 ел. | Юридик затның атмосфера һавасын саклауны контрольдә тотуны махсус төзелгән хезмәткә яисә билгеләнгән җаваплы затка йөкләү турында боерыгы (әмернамәсе);<br>Махсус төзелгән (экологик) хезмәт турында нигезләмә;<br>Экология хезмәте хезмәткәрләренең (экологның) вазифаи күрсәтмәләре;<br>Экология хезмәте хезмәткәрләренең (экологның) кирәкле һөнәри әзерлеген яисә яңадан укыганлыгын раслаучы документлар;<br>Атмосфера һавасын саклауга (шул исәптән ПДВ (ВСВ) үтәлешенә) җитештерү контролен оештыру һәм үткәрү тәртибе (предприятиенең, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | оешманың юридик зат тарафыннан расланган экологик контроле турындагы нигезләмәсе составында);<br>Ташландык чыганакларында һәм контрольлек нокталарында (постларында) ПДВ нормативларының үтәлешен контрольдә тотуның план-графигы;<br>Зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларының җитештерү контроле нәтиҗәләре (атмосфера һавасындагы рөхсәт ителгән зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең рөхсәт ителүче чик коцентрацияләре буенча ачыкланган артулар турындагы күрсәткечләрне күрсәтергә кирәк: матдәләрнең кодын, аның исемен, билгеләнгән ПДК, матдә концентрациясен (мг/куб. метрда) һәм кабатлануын (ПДК артуның ешлыгын); предприятие лабораториясенең аккредитациясе турындагы аттестатның күчермәсе (лаборатория булган очракта) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | – җитештерүдә ташландыкларны һәм зарарлы физик йогынтыларны җайга сала торган технология регламентын, технология күрсәтмәләрен үтәү | Атмосфера һавасына пычраткыч матдә ташландыкларын хисаплау, нормалаштыру һәм контрольдә тоту буенча методик пособие (тулыландырылган һәм эшкәртелгән), "НИИ Атмосфера" ААҖ, С-Пб ш., 2012 ел. | Җитештерүдәге технология регламентлары, технология күрсәтмәләре |
| | – пычраткыч матдәләрнең пробаларын сайлап алу һәм анализлау һәм атмосфера һавасына физик йогынтыларның дәрәҗәсен билгеләү буенча кулланмаларны, методик күрсәтмәләрне үтәү | Атмосфера һавасына пычраткыч матдә ташландыкларын хисаплау, нормалаштыру һәм контрольдә тоту буенча методик пособие (тулыландырылган һәм эшкәртелгән), "НИИ Атмосфера" ААҖ, С-Пб ш., 2012 ел. | Пычраткыч матдәләрнең пробаларын сайлап алу һәм анализлау һәм атмосфера һавасына физик йогынтыларның дәрәҗәсен билгеләү буенча кулланмалар, методик күрсәтмәләр |
| | – атмосфера һавасына булган зарарлы йогынтыларны контрольдә тотуга юнәлдерелгән корылмалардан, җайланмалардан файдалану кагыйдәләрен үтәү | Атмосфера һавасына пычраткыч матдә ташландыкларын хисаплау, нормалаштыру һәм контрольдә тоту буенча методик пособие (тулыландырылган һәм эшкәртелгән), "НИИ Атмосфера" ААҖ, С-Пб ш., 2012 ел. | Атмосфера һавасына булган зарарлы йогынтыларны контрольдә тотуга юнәлдерелгән корылмалардан, җайланмалардан файдалану кагыйдәләре; контрольлек итү җайланмаларының паспортлары; контрольлек итү җайланмаларын соңгы тапкыр тикшерү актларының күчермәләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | – әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен (стационар чыганаклардан атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр ташлаган өчен) түләүләр | “Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” 01.01.2002, № 7-ФЗ Федераль законның 16 ст.;<br>04.05. 1999, №96-ФЗ ФЗ 28 статьясы | Түләү йөкләмәләренең күчермәләре;<br>Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләүләрне башкару турында квартал саен тапшырылучы декларацияләр |
| | 4. Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларының стационар чыганаклары булган объектларның санитар-сак зоналары тәртибен саклау | 04.05.1999, №96-ФЗның 24 статьясының 1 пункты, 30 статьясының 1 пункты;<br>РФ Баш дәүләт санитария табибының “Санитария кагыйдәләрен гамәлгә кертү турында”гы 17.05.2001, №14 боерыгы белән расланган “Торак урыннардагы атмосфера һавасының сыйфатын тәэмин итүгә карата гигиена таләпләре”, СанПиН 2.2.6 1032-01;<br>“Предприятиеләрнең, корылмаларның һәм башка төр объектларның санитар-сак зоналары һәм санитар классификациясе”, СанПиН 2.2.1/2.1.1 1200-03 | Санитар-сак зоналарында зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларына җитештерү контроле нәтиҗәләре;<br>Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларының стационар чыганаклары булган объектларда санитар-сак зонасы тәртибенең үтәлешен тикшерү өлешендә дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеген башкаручы органнарның актлары һәм күрсәтмәләре;<br>бозуларны бетерү буенча чаралар күрелү турында хисаплар |
| | 5. Атмосфера һавасындагы зарарлы | 04.05.1999, №96-ФЗның 30 статьясының 1 пункты; | Атмосфера һавасындагы зарарлы (пычраткыч) матдә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | (пычраткыч) матдә ташландыкларын инвентаризацияләү һәм атмосфера һавасына мөмкин булган ташландыкларның мөмкин булган һәм зарарлы физик йогынтыларның мөмкин булган чик нормативларын эшләп чыгару | 05.06.2013, № 476 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмәнең 9 пункты; Атмосфера һавасында предприятиеләрнең зарарлы матдә ташландыкларының концентратын хисаплау методикасы. СССРның гидрометеорология һәм табигый тирәлекне контрольдә тоту буенча дәүләт комитеты тарафыннан расланган ОНД-86, 04.08.1986, № 192;<br>ГОСТ 17. 2. 3. 02 -78<br>Сәнәгать предприятиеләренә мөмкин булган зарарлы матдә ташландыкларын билгеләү кагыйдәләре;<br>Атмосфера һавасындагы пычраткыч матдә ташландыкларын хисаплау, нормалау һәм контрольдә тоту буенча Ростехнадзор Хаты белән гамәлгә кертелгән методик ярдәмлек, 24.12.2004 ел, №14-01-333 | ташландыкларын инвентаризацияләү буенча предприятиенең җитәкчесе тарафыннан расланган хисап; атмосфера һавасына мөмкин булган зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең чик нормативлары проекты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 6. Табигатьне саклау буенча атмосфера һавасын саклауда дәүләт контролен башкаручы инспекторларның Россия Федерациясенең атмосфера һавасын саклау өлкәсендәге законнарының таләпләре бозылуны бетерү турындагы күрсәтмәләрен үтәү | 05.06.2013, № 476 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмәнең 9 пункты; | Атмосфера һавасын саклау буенча дәүләт контролен (дәүләт экология контролен) башкарганда предприятиегә карата үткәрелгән элеккеге тикшерүләрнең нәтиҗәләренә кагылышлы документлар: элеккеге тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча актлар һәм күрсәтмәләр; административ хокук бозулар турында беркетмәләр (карарлар); предприятие буенча боерыклар һәм табигатьне саклау законнарын бозуларны бетерү буенча чараларның планнары; табигатьне саклау законнарын бозуларны бетерү буенча үткәрелгән чаралар турында хисаплар |
| | 7. Атмосфера һавасын саклау буенча программаларның һәм чараларның үтәлеше | 04.05.1999, №96-ФЗ ФЗ 24 статьясының 1 пункты, 30 статьясының 1 пункты; 05.06.2013, № 476 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмәнең 9 пункты; | Атмосфера һавасын саклау буенча программалар (булган очракта); атмосфера һавасын саклау буенча үтәлгән программалар (булган очракта) буенча хисаплар; предприятиеләрнең |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | РФ Баш дәүләт санитария табибының “Санитария кагыйдәләрен гамәлгә кертү турында”гы 17.05.2001, №14 боерыгы белән расланган СанПиН 2.2.6 1032-01 “Торак урыннардагы атмосфера һавасының сыйфатын тәэмин итүгә карата гигиена таләпләре”; ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 09.05.2003, №491 боеырыгы белән расланган Татарстан Республикасы предприятиеләренең һәм оешмаларының табигатьне саклау чаралары планнарын төзү буенча тәкъдимнәр | (оешмаларның) табигатьне саклау чаралары планнары; ПОД-2 “Атмосфера һавасын саклау буенча чараларның үтәлешен исәпкә алу журналы” |
| | шул исәптән: | | |
| | 7.1. Атмосфера һавасының пычрану дәрәҗәсен киметү максатларында азкалдыклы һәм калдыксыз технологияләр кертү | 04.05.1999, №96-ФЗның 30 статьясының 1 пункты; 05.06.2013, № 476 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмәнең 9 пункты; | Атмосфера һавасын саклау буенча программалар (булган очракта); атмосфера һавасын саклау буенча үтәлгән программалар (булган очракта) буенча хисаплар; предприятиеләрнең (оешмаларның) табигатьне |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | саклау чаралары планы;<br>ПОД-2 “Атмосфера һавасын саклау буенча чараларның үтәлешен исәпкә алу журналы” |
| | 7.2. Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) ташландыкларны тотып калу, юк итү, зарарсызландыру, мондый ташландыкларны киметү яисә булдырмый калу буенча чаралар күрү | 04.05.1999, №96-ФЗның 30 статьясының 1 пункты;<br>05.06.2013, № 476 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмәнең 9 пункты; | шул ук |
| | 7.3. Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) аварияле ташландыкларны кисәтү, һәм шулай ук аның нәтиҗәсендәге пычракларны бетерү буенча чаралар күрү | 04.05.1999, №96-ФЗның 30 статьясының 1 пункты;<br>05.06.2013 елдан № 476 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмәнең 9 пункты;<br>РФ Баш дәүләт санитария табибының “Санитария кагыйдәләрен гамәлгә кертү турында” 17.05.2001, №14 боерыгы белән расланган “Торак урыннардагы атмосфера һавасын сыйфат белән тәэмин итүгә | Атмосфера һавасын саклау буенча программалар (булган очракта);<br>атмосфера һавасын саклау буенча программаларның (булган очракта) үтәлеше буенча хисаплар;<br>предприятиенең (оешманың) табигатьне саклау чаралары планы;<br>ПОД-2 “Атмосфера һавасын саклау буенча чараларның үтәлешен исәпкә алу журналы” |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | карата гигиена таләпләре” СанПиН 2.2.6  1032-01 | |
| | 8. Атмосфера һавасын саклау кагыйдәләрендә каралган, атмосфера һавасын зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларыннан чистартуга һәм контрольдә тотуга, һәм шулай ук аларны файдалану буенча билгеләнгән кагыйдәләрне үтәүгә юнәлдерелгән корылмаларның, җайланмаларның булуы, | 04.05.1999, №96-ФЗның 30 статьясының 1 пункты; 05.06.2013, № 476 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмәнең 9 пункты; | ПОД-1 “Пычратуның стационар чыганакларын исәпкә алу һәм аларның сыйфатламалары журналы” |
| | шул исәптән: | | |
| | 9. Булган газчистарткыч (тузан тотып калучы) җайланманың, әгәр дә андый (корым тотып калучылар, циклоннар, тузан утырткыч камералар, аер сөзгечләре, гидросөзгечләр һ.б.) | Газчистарткыч җайланмалардан файдалануга карата Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 02.08.2004, №761 боерыгы белән расланган гомуми таләпләр | ПОД-3 “Газчистарткыч һәм тузан тотып калучы җайланмаларның эшен исәпкә алу журналы”; газчистарткыч һәм тузан тотып калучы җайланмаларның эшен исәпкә алу журналын алып бару тәртибе турында боерык; һәр газ чистарту җайланмасының паспорты; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | булса, төзек торыштагы файдаланылышын тәэмин итү | | газ чистарту җайланмаларының нәтиҗәле эшләвен тикшерү актлары |
| | 10. Атмосфера һавасын пычратучы калдыкларны хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектлары территорияләреннән мондый калдыкларны урнаштыруның яисә саклауның махсус урыннарына, шулай ук хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектларына үз вакытында чыгаруны тәэмин итү | 04.05.1999, №96-ФЗның 18 статьясы, 30 статьясының 1 пункты; | Предприятиенең калдыклар белән эш итү өлкәсендәге (атмосфера һавасын пычратучы калдыкларны үз вакытында чыгару өлешендә) эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге документлар: |
| | | 05.06.2013, №476 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Атмосфера һавасын саклауның дәүләт контроле турында нигезләмәнең 9 пункты | предприятиене тикшерү нәтиҗәләре буенча актлар һәм күрсәтмәләр;<br>административ хокук бозулар турында беркетмәләр (карарлар);<br>предприятие буенча боерыклар һәм законнарның бозылышын бетерү буенча чаралар планы;<br>күрсәтмәләрнең һәм актларның үтәлеше турында хисаплар |
| | 11. Начар метеорология | 04.05.1999, №96-ФЗ | Начар метеорология |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | шартларында атмосфера һавасындагы зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын киметү буенча чаралар үткәрү | 19 статьясының 3 өлеше | шартларында атмосфера һавасындагы зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын киметү буенча чаралар планы һәм аларның нәтиҗәлелек бәяләмәсе |
| Атмосферага пычраткыч матдә ташландыкларының күчмә чыганаклары, шул исәптән транспорт һәм башка төр күчмә чаралары булган хуҗалык итүче субъектлар | | 05.06.2013, №476 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Атмосфера һавасын саклауның дәүләт контроле турында нигезләмәнең 9 пункты | 52.04.52-85 ЖД таләпләре нигезендә чараларны үтәү турында журнал |
| | 12. Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты (күчмә чыганаклардан атмосфера һавасына пычраткыч матдә ташландыклары) өчен түләүләр башкару | “Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” 10.01.2002, №7-ФЗ Федераль законның 16 статьясы; 04.05.1999, №96-ФЗ Федераль законның 28 статьясы | Түләү йөкләмәләренең күчермәләре;<br>әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләүләрне башкару турында квартал саен тапшырыла торган декларацияләр;<br>атмосфераны пычратучы күчмә чыганаклар турында мәгълүматлар (автомобильләрнең төркемнәре, барлык һәм файдаланууда булган транспорт чараларының күләме, транспорт |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | берәмлегенең ел саен чабып үткән юлы (мең чакрымнарда), төрләр буенча күчерелгән ягулык күләме һ.б.: предприятиенең төп суммалары буенча бухгалтерлык-исәп документлары (№01, 02, 47 исәп документлары); автотранспортны арендага бирү (алу) турындагы килешүләрнең күчермәләре (№03 исәп); автотранспорт чараларыннан файдалануның көн саен исәбе алып барылучы журнал; көн саен тотылучы ягулык журналы; үтелгән чакрымнар журналы; бензин двигательле автомобильләрне экология таләпләренә туры килүе буенча тикшерүнең нәтиҗәләрен теркәү журналы; дизель двигателеннән эшләүче автомобильләрне тикшергәндә төтен чыгару үлчәмнәрен исәпкә алу журналы |
| | 13. Автотранспорт чараларының газ чыгару | РФ КоАП 8.21-8.23, 23.29 | Автомобильләрне агулылыкка |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | торбаларынннан пычраткыч ташландыкларны контрольдә тоту | статьялары;<br>04.05.1999, №96-ФЗ ФЗ 17 статьясының 1 пункты, 30 статьясының 2 пункты;<br>ГОСТ Р 52033-2003 “Бензин двигательле автомобильләр. Эшләнгән газ белән пычраткыч матдә ташландыклары. Техник торышны бәяләгәндә контроль нормалары һәм ысуллары”. Россия Дәүләт стандарты тарафыннан 27.03.2003 елдан расланган һәм гамәлгә кертелгән №100-ст.;<br>ГОСТ Р 52160-2003 “Кысудан кабынып китүче двигательләр белән җиһазланган автотранспорт чаралары. Эшләнгән газларның төтенлелеге. Техник торышны бәяләгәндә контроль нормалары һәм ысуллары”. Россия Дәүләт стандарты тарафыннан 2003 елның 18 декабрендә расланган һәм гамәлгә кертелгән №375-ст.;<br>ГОСТ Р 17.2.2.06-99 “Табигатьне саклау. Газ балонлы | (төтенләүгә) карата тикшерүләрне исәпкә алу журналы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | автомобильләрнең эшләнгән газларындагы углерод оскидын һәм углеводородларны үлчәү нормалары һәм ысуллары”. Россия Дәүләт стандарты тарафыннан 1999 елның 16 ноябрендә расланган һәм гамәлгә кертелгән №405-ст.;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 06.07.2005 ел, №325 карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы турында нигезләмәнең 3.3.3 пункты | |

## 4. Тикшерүне үткәргән вакытта юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан күрсәтелүче документлар

Атмосфера һавасын саклау буенча дәүләт күзәтчелеген башкарганда үткәрелүче тикшерүләрнең максатларын һәм бурычларын үтәү өчен юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан күрсәтелүче документлар исемлеге, һәм шулай ук мондый документларның рәвешенраслый торган норматив-хокукый актлар 3 нче таблицада күрсәтелгән.

**3 нче таблица**. Тикшерү үткәрүнең максатларын һәм бурычларын үтәү өчен юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан күрсәтелүче документлар исемлеге

| Тикшерүне үткәрү өчен күрсәтелә торган документ | Документның рәвешен билгели торган норматив-хокукый акт |
|---|---|
| **Атмосферага пычраткыч матдә ташландыкларының стационар чыганаклары булган хуҗалык итүче субъектлар** | |
| 1. Аерым төр эшмәкәрлек эшчәнлеген башлап җибәрү турында белдерүнамә (Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган эшләр һәм хезмәтләр исемлеге нигезендә эшләр һәм хезмәтләр башкаручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен) | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Аерым төр эшмәкәрлек эшчәнлеген башлауны хәбәр итү тәртибе турында” 16.07.2009, № 584 карары |

| | |
|---|---|
| 2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларына һәм аңа зарарлы физик йогынтыларга бирелгән рөхсәт | ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларына рөхсәтләрне бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 20.04.2012, № 134-п боерыгы |
| 3. Атмосфера һавасын саклау буенча контрольлек итүне махсус булдырылган хезмәткә яисә билгеләнгән җаваплы затка йөкләү турында юридик зат боерыгы (әмернамәсе) | – |
| 4. Махсус булдырылган (экологик) хезмәт турында нигезләмә | – |
| 5. Экология хезмәте хезмәткәрләренең (экологның) вазифаи инструкцияләре | – |
| 6. Атмосфера һавасын саклау, шул исәптән ПДВ (ВСВ) үтәлеше) (юридик зат тарафыннан расланган предприятиенең, оешманың экология контроле турында нигезләмәсе составында) буенча җитештерү контролен оештыру һәм үткәрү тәртибе | – |

| | |
|---|---|
| 7. Предприятиедәге ташландык чыганакларында һәм контрольлек нокталарында (постларында) ПДВ нормативларын саклауның план-графигы, пробаларны алу актларын һәм күләм-химик анализ беркетмәләрен күрсәтү белән берлектә, аның узган елдагы үтәлеше турында хисап | – |
| 8. Зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларына җитештерү контроле нәтиҗәләре (атмосфера һавасындагы рөхсәт ителгән зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең рөхсәт ителүче чик концентрацияләре буенча ачыкланган артулар турында күрсәткечләрне күрсәтергә кирәк: матдәләрнең кодын, аның исемен, билгеләнгән ПДК, матдә концентрациясен (мг/куб. метрда) һәм ешлыгын (ПДК артуның ешлыгын) | – |
| 9. Предприятие лабораториясенең аккредитациясе турында аттестат күчермәсе (лаборатория булган очракта) | – |
| 10. Җитештерүдәге технология регламентлары, технология кулланмалары | – |
| 11. Пычраткыч матдәләрнең пробаларын алу һәм анализлау һәм атмосфера һавасына физик йогынтыларның дәрәҗәсен билгеләү буенча кулланмалар, методик күрсәтмәләр | – |
| 12. Атмосфера һавасына зарарлы йогынтыларны контрольдә тотуга юнәлдерелгән корылмалардан, җайланмалардан файдалану кагыйдәләре | – |
| 13. Контрольлек итү җайланмаларының паспортлары | – |

| | |
|---|---|
| 14. Контрольлек итү җайланмаларын соңгы тапкыр тикшер актларының күчермәләре | – |
| 15. Әйләнә-тирә мохиткә (шул исәптән транспорт чараларыннан файдаланганда) тискәре йогынты өчен түләү башкаруны раслаучы документлар:<br>түләү йөкләмәләренең күчермәләре;<br>әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләүне башкару буенча квартал саен тапшырылучы декларацияләр | – |
| 16. Санитар-сак зоналарында зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларына җитештерү контроленең нәтиҗәләре | – |
| 17. Атмосфера һавасындагы зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын инвентаризацияләү буенча предприятиенең җитәкчесе тарафыннан расланган хисап | Атмосфера һавасындагы пычраткыч матдә ташландыкларын инвентаризацияләү буенча кулланма (СССР Госкомприрода расл.). – Л, "Звание" РСФСР Ж-те. Ленингр. Оешма. ЛДНТП, 1991 |
| 18. Атмосфера һавасына мөмкин булган зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең чик нормативлары яисә пычраткыч матдә ташландыкларына лимитлар проекты | ГОСТ 17.2.3.02-78 СССР Дәүләт стандарты. Табигатьне саклау. Атмосфера.<br>Сәнәгать предприятиеләре тарафыннан мөмкин булган зарарлы матдә ташландыкларын билгеләү кагыйдәләре. (24.08.1978, №2329 СССР Дәүләт стандарты Карары белән расл.) |

| | |
|---|---|
| 19. Дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе | – |
| 20. Предприятиенең санитар-сак зонасын оештыруның билгеләнгән тәртиптә килештерелгән проекты | – |
| 21. Агымдагы елга санитар-сак зонасында атмосфера һавасын мониторинглау планы (проекты), пробалар алу актларын һәм КХА беркетмәләрен күрсәтеп, аның узган елдагы үтәлеше буенча хисап | – |
| 22. Атмосфера һавасын саклау буенча программалар (булган очракта);<br>Атмосфера һавасын саклау буенча программаларны үтәү турында хисаплар | – |
| 23. Предприятиенең (оешманың) табигатьне саклау чаралары планы | – |
| 24. ПОД-2 “Атмосфера һавасын саклау буенча чараларның үтәлешен исәпкә алу журналы” | – |
| 25. Газчистарткыч җайланмаларны файдалану, карап тоту һәм төзекләндерү буенча җаваплы затларны билгеләү турында предприятие (оешма) боерыгы (әмернамәсе) | – |
| 26. Газчистарткыч җайланмаларны файдалану, карап тоту һәм төзекләндерү белән мәшгуль булган персонал, һәм шулай ук җайланмаларның техник торышын контрольдә тотучы белгечләр өчен вазифаи күрсәтмәләр | – |

| | |
|---|---|
| 27. ПОД-1 “Стационар пычрату чыганакларын исәпкә алу һәм аларның сыйфатламалары журналы” | – |
| 28. ПОД-3 “Газчистарткыч һәм тузан тотып кала торган җайланмаларның эшен исәпкә алу журналы” | – |
| 29. Газчистарткыч һәм тузан тотып кала торган җайланмаларның эшен исәпкә алу журналларын алып бару тәртибе турында боерык | |

| | |
|---|---|
| 30. Файдалану буенча документлар тупланмасы<br>Һәр газ чистарту җайланмасы өчен:<br>– газларны чистарту җайланмасының һәркайсын урнаштыруга билгеләнгән формадагы паспорт;<br>– техник тасвирламалары һәм файдалану һәм карап тоту буенча күрсәтмәләре белән, газдан чистартучы аппаратларның, җайланма составындагы җайланмаларның, төеннәрнең, җиһазларның җитештерүче заводларыннан бирелгән паспортлары;<br>– аерым газчистарткыч җайланмасын файдалану һәм карап тоту буенча күрсәтмә;<br>– газчистарткыч җайланманың нәтиҗәлелеген тикшерү эшләре буенча план;<br>– газны чистарту җайланмаларын планлы-кисәтүле (агымдагы) төзекләндерү графигы;<br>– газчистарткыч җайланмаларны файдалану һәм карап тоту буенча җаваплы затлар карамагына файдалану һәм норматив-техник документлар тупланмасындагы башка документлар.<br>(Паспортка тәмамланган төзелештән соң, реконструкциядән соң, капиталь һәм планлы-кисәтүле төзекләндерүләрдән соң җайланманы файдалануга кабул итү актлары; эшләү нәтиҗәлелеген тикшерү актлары; газчистарткыч җайланманың техник торышын тикшерү һәм бәяләү актлары теркәлергә тиеш. Газчистарткыч җайланманы кабул итү актының рәвеше билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш). | “Газ чистарту җайланмаларын эксплуатацияләү кагыйдәләре” (“Газ чистарту җайланмасы паспортын тутыру буенча инструкция” белән берлектә) (28.11.1983, СССР Минхиммаш тараф. расл.)<br>Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының газчистарткыч җайланмалардан файдалану буенча 02.08.2004, №761 боерыгы белән расланган гомуми таләпләр |
| 31. Начар метеорология шартларында атмосфера һавасындагы зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын киметү буенча чаралар планы һәм аларның ТР ЭТРМ тарафыннан килештерелгән нәтиҗәлелек бәяләмәсе | – |

| | |
|---|---|
| 32. Чараларның ЖД 52.04.52-85 таләпләре нигезендә үтәлеше турындагы журнал | Методик күрсәтмәләр. Начар метеорология шартларында ташландыкларны җайга салу. ЖД 52.04.52-85 (01.12.1986 СССР Госкомгидромет тараф. расл.) |
| 33. Начар метеорология шартлары чорында предприятие, җитештерүләр, цехлар, кишәрлекләр һәм башка объектлар буенча җаваплы затларны, һәм шулай ук хәбәрләштереп торуны оештыруга һәм ташландыкларны киметү буенча чаралар алып баруга җаваплы затларны билгеләп, кушылган эш тәртипләренә көчү турында предприятие җитәкчесе боерыгының күчермәсе | – |
| 34. Яңа продукция җитештерүгә технология регламентлары (җитештерү технологиясен үзгәрткән очракта ташландыкларның мөмкин булган яңа чик нормаларын билгеләү таләп ителә, шуңа күрә элегрәк бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертелүне тикшерергә кирәк) | – |
| 35. Яңа продукциягә карата стандартлар, техник шартлар | – |
| 36. Яңа продукция төрләреннән һәм яңа технологияләрдән йогынты алучы атмосфера һавасының торышын контрольдә тоту ысуллары | – |
| 37. Түбәндәгеләрнең ярашлылыгын дәлилләүче сертификатлар:<br>– ягулыкның атмосфера һавасын саклау таләпләренә;<br>– техника, технология җайланмаларыннан зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыклары күләменең техник нормаларга | – |

| Атмосферага пычраткыч матдә ташландыкларының күчмә чыганаклары, шул исәптән автотранспорты булган хуҗалык итүче субъектлар | |
|---|---|
| 38. Атмосфераны пычратучы күчмә чыганаклар турында мәгълүматлар (автомобильләрнең төркемнәре, барлык һәм файдаланудагы булган транспорт чараларының күләме, транспорт берәмлегенең ел саен чабып үткән юлы (мең чакрымнарда), төрләр буенча күчерелгән ягулык күләме һ.б.:<br>– предприятиенең төп суммалары буенча бухгалтерлык-исәп документлары (№01, 02, 47 счетлар);<br>– автотранспортны арендага бирү (алу) турында килешүләрнең күчермәләре (№03 счет);<br>– автотранспорт чараларыннан файдалануның көн саен исәбе алып барыла торган журнал;<br>– көн саен тотылучы ягулык журналы;<br>– үтелгән чакрымнар журналы;<br>– бензин двигательле автомобильләрне экология таләпләренә туры килүе буенча тикшерүнең нәтиҗәләрен теркәү журналы;<br>– дизель двигателеннән эшләүче автомобильләрне тикшергәндә төтен чыгару үлчәмнәрен исәпкә алу журналы | – |
| 39. Двигательләрдән, транспорт һәм башка күчмә чаралардан һәм җайланмалардан зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыклары күләменең техник нормаларга туры килүен дәлилләүче сертификатлар | – |

## 5. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкаруның составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре

Дәүләт күзәтчелеге юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы (документар һәм урынга чыгып) һәм планнан тыш (документар һәм урынга чыгып) тикшерүләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге Регламент түбәндәге административ процедураларның үтәлешен күздә тота:

юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планлы документар тикшерү үткәрү;

юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү;

юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү;

юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү;

Дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелә.

Дәүләт функциясен үтәүне туктату Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

### 5.1. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.1.1. Тиешле юридик затны, шәхси эшмәкәрне еллык Планга кертү “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлау өчен нигез булып тора. Юридик затны, шәхси эшмәкәрне планлы тикшерүне еллык Планга кертү әлеге Регламентның 2.3.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрдә башкарыла.

“Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планлы документар тикшерү

үткәрү” административ процедурасы түбәндәге эш тәртипләре буенча гамәлгә ашырыла:

планлы документар тикшерүне үткәрүгә җаваплы вазифаи затларны билгеләү карарын кабул итү;

планлы документар тикшерү үткәрү турында боерык (әмернамә) формалаштыру;

юридик затка, шәхси эшмәкәргә планлы документар тикшерү үткәрү турында хәбәр җиткерү;

планлы документар тикшерүне үткәрү;

үткәрелгән планлы документар тикшерүнең нәтиҗәләрен формалаштыру.

5.1.2. Тикшерүләр планы нигезендә ТР ЭТРМ Дәүләт күзәтчелеге инспекциясе башлыгы (ТР ЭТРМ территориаль идарәсе башлыгы):

ТР ЭТРМ вазифаи затлары арасыннан җаваплы башкаручыларны билгели, шул ук вакытта, әлеге Регламентның 2.5 п. нигезендә, тикшерүне үткәрүче вазифаи затның (алга таба – җаваплы башкаручы) юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү үткәрү вәкаләтләренә ия булуы карарны кабул итүгә критерий булып тора;

кирәк булган очракта тикшерелүче юридик зат, шәхси эшмәкәр белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт килешүләре мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелүче затларның аффилир затлары булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итә.

Үтәү вакыты: үткәреләчәк тикшерүне башлар алдыннан биш эш көне дәвамында яисә еллык Планны төзегәннән соң турыдан-туры.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү үткәрү өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы.

5.1.3. Җаваплы башкаручы:

юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү үткәрү турында ТР ЭТРМ боерыгын (әмернамәсен), җаваплы башкаручыларга, ТР ЭТРМ Үзәк махсуслашкан аналитика контрольлеге инспекциясе белгечләренә юридик

затның (шәхси эшмәкәрнең) объектларында күзәтчелек чараларын үткәрү өчен әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы рәвешендә план-биремен әзерли;

әмернамә проектын министрга (министр урынбасарына) имзалау өчен юллый.

Үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата үткәреләчәк тикшерү турында хәбәр итү вакытын (хәбәр итү вакыты хәбәр җиткерүнең ысулыннан чыгып билгеләнә) исәпкә алмыйча, тикшерүне үткәрә башлаганчы өч эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: тикшерүне үткәрү турында министр (министрның урынбасары) тарафыннан имзаланган боерык.

5.1.4. Җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү үткәреләчәге турында тикшерүне үткәрү турында, әмернамә күчермәсен почта аша заказлы хат җибәрү юлы белән, яисә башка үтемле ысул (факсимиль элемтә, электрон почта аша, атап, кулга алу турында тамгасы белән) ярдәмендә хәбәр итә.

Үтәү вакыты: үткәреләчәк тикшерү башланыр алдыннан өч эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшмәкәр адресына юлланган тикшерүне үткәрү турындагы боерыкның (әмернамәнең) күчермәсе.

Үзен-үзе җайга салучы оешманың әгъзаларына планлы тикшерү үткәрелгәндә, җаваплы башкаручы үзен-үзе җайга салучы оешмага, тикшерү башланырга өч эш көне кала, аның вәкиленә үткәрелүче планлы тикшерүдә катнашу яисә булу мөмкинлеген тудыру максатларында белдерүнамә юллый.

Юридик зат, шәхси эшмәкәр ун эш көне дәвамында тикшерү үткәрү турындагы әмернамә күчермәләрендә күрсәтелгән документларны мөһер (булган очракта) һәм шулай ук шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең, башка вәкаләтле затының имзасы белән рәсмиләштерелгән күчермәләре рәвешендә ТР ЭТРМ юлларга бурычлы.

Юридик зат, шәхси эшмәкәр гарызнамәдә күрсәтелгән әлеге

документларны, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган тәртиптә, электрон документлар рәвешендә дә юллый ала.

5.1.5. Җаваплы башкаручы ТР ЭТРМ карамагындагы документларның мәгълүматлары һәм юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан тапшырылган документлардагы белешмәләр нигезендә:

мәгълүматларның дөреслеген тикшерә;

юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлегенең билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры килүенә карата документлардагы мәгълүматларга бәя бирә.

Әгәр документлардагы мәгълүматларның дөреслеге шик тудырса, яисә әлеге мәгълүматлар мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирмәсә, әгәр дә ТР ЭТРМ тапшырылган документлардагы мәгълүматларның хаталы һәм (яисә) каршылыклы, туры килми торган булуы ачыкланса, җаваплы башкаручы:

юридик зат, шәхси эшмәкәр адресына ун эш көне дәвамында язмача рәвештә кирәкле аңлатмаларны яисә карау өчен кирәкле булган башка документларны тапшыруны таләп итеп, һәм белешмәләрне бәяләүнең нәтиҗәләре турында мәгълүматларны һәм нигезле гарызнамәне үз эченә алган хат әзерли;

хатны, имзалатып кулга тапшыру яисә кулга алу турында тамгасын кую хәбәрен җибәрү юлы белән, почта аша заказлы хат итеп юллый.

Үтәү вакыты: үткәреләчәк тикшерү башланыр алдыннан биш эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшмәкәр адресына юлланган, документларны таләп итүле (нигезле гарызнамәле) хат.

5.1.6. Җаваплы башкаручы мәҗбүри тәртиптә юридик зат, шәхси эшмәкәр тапшырган документларны һәм (яисә) аңлатмаларны карап тикшерә. Тапшырылган аңлатмаларны һәм (яисә) документларны карап тикшергәннән соң яисә аңлатмалар булмаган очракта, әлеге Регламентның 3 нче бүлегендә күрсәтелгән мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре ачыкланса, җаваплы башкаручы урынга чыгып тикшерү үткәрү турында боерык (әмернамә)

проектын әзерләү юлы белән урынга чыгып тикшерү үткәрүнең инициаторы була.

Урынга чыгып тикшерү (аны үткәрү турында карар кабул ителгән очракта) әлеге Регламентның 5.2 пунктында күрсәтелгән тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карарны министр (министр урынбасары) кабул итә.

Урынга чыгып тикшерү үткәрү зарурлыгы турында карар кабул итүнең критерие булып юридик зат, шәхси эшмәкәр тапшырган документларны һәм (яисә) аңлатмаларны карап тикшерү барышында урынга чыгып тикшерү үткәрү өчен нигез булып торучы мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләренең ачыклануы тора.

Үтәү вакыты: аңлатмаларны һәм (яисә) документларны алганнан соң өч эш көне дәвамында.

Эш нәтиҗәсе: җаваплы башкаручы тарафыннан карап тикшерелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр тапшырган документлар һәм (яисә) аңлатмалар; кирәк булганда урынга чыгып тикшерү үткәрү турында әмернамә проекты.

5.1.7. Җаваплы башкаручы планлы документар тикшерү нәтиҗәләре буенча юридик затны, шәхси эшмәкәрне тикшерү турында ике нөсхәдә ТР ЭТРМ актын төзи.

Мәҗбүри таләпләрне контрольдә тоту чаралары нәтиҗәсендә бозулар ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы законнарны үтәүгә юнәлдерелгән чираттагы чараларны (ачыкланган бозулар нәтиҗәсендәге зыянны каплау) гамәлгә ашыра:

тикшерү актында ачыкланган барлык бозуларны терки;

ачыкланган бозуларны бетерү турында, аларны бетерү һәм (яисә) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерүне, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның милкенә, дәүләт яисә муниципаль

милеккә булган зарарны, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны булдырмый калу буенча чараларны, һәм шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны үткәрү вакытларын күрсәтеп, мәҗбүри үтәлергә тиешле, тикшерү актына кушымта булучы (һәр бозу буенча аерым күрсәтмә) күрсәтмәләр (күрсәтмәнең рәвеше әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән) бирә, һәм әлеге күрсәтмәләрнең билгеләнгән вакытларда әлеге Регламентта каралган тәртиптә үтәлешен контрольдә тота;

РФ КоАП 8.1 ст., 8.4 ст., 8.5 ст., 8.21-8.23 ст., 8.41 ст., 19.4 ст. 1 ө., 1 19.5 ст. 1 ө., 19.6 ст., 19.7, 19.33 ст. каралган административ хокук бозу күренешләре ачыкланганда, законда билгеләнүче тәртиптә каралучы административ хокук бозулар турында эшләр кузгата.

Әгәр дә контроль буенча чаралар барышында контрольлек чаралары үткәрелүче хуҗалык яисә башка эшчәнлек объектының законнардагы таләпләрнең бозылуына бәйле булуы ачыкланса, бу бозуларны ачыклау, булдырмый калу һәм бетерү мәсьәләләре ТР ЭТРМ компетенциясенә карамаса, ТР ЭТРМ мондый бозулар турындагы мәгълүматларны (белешмәләрне) Россия Федерациясенең яисә Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына (Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча ТР территориаль агентлыгы (“Татарнедра”), Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең ТР Идарәсе, Экология һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең ТР Технология һәм экология күзәтчелеге идарәсе (Ростехнадзор), Ветеринар һәм фитосанитар күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең ТР Идарәсе, РФ ТРМ Түбән Идел су бассейны идарәсенең ТР су ресурслары бүлеге, Кулланучыларның хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт идарәсе, “Средволгаводхоз” су хуҗалыгы буенча ФДИ, ТР Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Казан

районара табигатьне саклау прокуратурасы, ТР Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе) юлларга бурычлы.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентының 1 нче кушымтасындагы рәвештә төзелгән тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталары белән берлектә) җаваплы башкаручы эшкә беркетә, икенчесен, тикшерү акты белән танышу яисә танышудан баш тарту турында имза куйдырып, юридик зат җитәкчесенә, башка вазифаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә (кушымталары белән берлектә) тапшыра.

Юридик затның җитәкчесе, башка вазифаи заты яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле урында булмаган очракта, һәм шулай ук тикшерелүче зат тикшерү акты белән танышу яисә танышудан баш тарту буенча имза куюдан баш тарткан очракта, акт кулга тапшыру белдерүнамәсе белән почта аша, заказлы хат итеп җибәрелә, белдерүнамә тикшерү актының Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентының 1 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә ТР ЭТРМ саклanучы эшкә теркәлүче нөсхәсе беркетелә.

Үтәү вакыты:

– Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентының 1 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә төзелгән тикшерү актын тапшыру: тикшерүне тәмамлаганнан соң турыдан-туры;

– тикшерү актын, контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру

буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентының 1 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә заказлы хат итеп җибәрү: контроль буенча чара тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аның беренчесе юридик затка, шәхси эшмәкәргә тапшырылган (юлланган), икенчесе эшкә беркетелгән.

5.1.8. Үзен-үзе җайга салучы оешма әгъзаларының мәҗбүри таләпләрне бозуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы үзен-үзе җайга салучы оешмага ачыкланган бозулар турында үткәрелгән тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көне дәвамында белдерүнамә юллый.

5.1.9. “Юридик затны, шәхси эшмәкәрне планлы документар тикшерү” административ процедурасын үтәүнең нәтиҗәсе ТР ЭТРМ рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

### 5.2. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.2.1. Тиешле юридик затны, шәхси эшмәкәрне ТР ЭТРМ еллык Планына кертү, һәм шулай ук үткәрелгән планлы документар тикшерүнең нәтиҗәсе булып торучы урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү турындагы әмернамә (әлеге Регламентның 5.1.6 пункты) “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлау өчен нигез булып тора, ягъни документар тикшерүдә:

1) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең ТР ЭТРМ карамагындагы документларында булган мәгълүматларның тулылыгына һәм дөреслегенә ышану;

2) юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген контрольдә тоту буенча тиешле чараларны үткәрмичә мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү мөмкин түгел.

Юридик затны, шәхси эшмәкәрне планлы тикшерүне планлы тикшерүләрне үткәрүнең еллык Планына кертү әлеге Регламентның 2.3.1

пунктларында күрсәтелгән нигезләрдә гамәлгә ашырыла.

“Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү” административ процедурасы әлеге Регламентның 5.1.1 пунктында күрсәтелгән аналогик административ гамәлләр тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2.2. Җаваплы затны, экспертларны билгеләү, юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата тикшерү үткәрү турында әмернамә әзерләү, юридик затка, шәхси эшмәкәргә үткәреләчәк тикшерү турында хәбәр итү әлеге Регламентның 5.1.2-5.1.4 пунктларында күрсәтелгән тәртиптә башкарыла.

5.2.3. Җаваплы башкаручы, экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең объектына килгәннән соң, тикшерүне түбәндәгеләрдән башлый:

– хезмәт таныклыкларын күрсәтә;

– юридик зат җитәкчесен яисә башка вазифаи затын, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен министрның (министр урынбасарының) урынга чыгып тикшерүне үткәрү турындагы әмернамәсе белән мәҗбүри таныштыра;

– юридик затның башка вазифаи затын, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен урынга чыгып тикшерүне үткәрүче затларның вәкаләтләре, һәм шулай ук максатлары, бурычлары, урынга чыгып тикшерүнең нигезләре, контроль буенча чараларның төрләре һәм күләмнәре, урынга чыгып үткәрелүче тикшерүгә җәлеп ителүче экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең составы, аны үткәрүнең вакытлары һәм шартлары белән мәҗбүри таныштыра.

Җаваплы башкаручылар, экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлегенең әлеге Регламентның 3 нче бүлегендә күрсәтелгән мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяли, шул исәптән күзәтчелек буенча чираттагы чараларны үткәрә:

оештыру-хокукый рәвешенең һәм милек рәвешенең нинди булуына карамастан, федераль дәүләт экология күзәтчелегендәге объектлардан гайре, хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектларын тикшерә, дәүләт күзәтчелеген

башкаруга кирәкле булган документлар һәм башка материаллар белән танышу максатларында юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә бара;

атмосфера һавасын саклау өлкәсендәге нормативларны, дәүләт стандартларын һәм башка норматив документларны үтәүне, зарарсызландыручы җайланмаларның, контроль чараларның эшен, һәм шулай ук әйләнә-тирә мохитне саклау буенча планнарның һәм чараларның үтәлешен тикшерә;

җитештерү белән бәйле һәм башка объектларны урнаштырганда, файдаланганда һәм файдаланудан чыгарганда атмосфера һавасын саклау өлкәсендәге таләпләрнең, нормаларның һәм кагыйдәләрнең үтәлешен тикшерә;

юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә, аларны бетерү вакытларын күрсәтеп, бозуларны бетерү турында һәм (яисә) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян салынуны, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның милкенә, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә зарарны булдырмый калу, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү буенча чаралар, һәм шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны үткәрү турында таләпләр куя һәм күрсәтмәләр бирә (күрсәтмәнең рәвеше әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелә) (күрсәтмә тикшерү актына кушымта булып тора һәм һәр бозу очрагы буенча аерым төзелә);

мәҗбүри таләпләрнең бозылышы буенча җаваплылык йөкләнгән юридик зат эшчеләреннән, шәхси эшмәкәр эшчеләреннән аңлатмалар ала;

административ хокук бозу турында беркетмә төзи, атмосфера һавасын саклау өлкәсендәге законнарның бозылуына юл куйган затларны билгеләнгән тәртиптә административ җаваплылыкка тарта.

ТР ЭТРМ аналитика контрольлегенең махсуслашкан инспекцияләренең белгечләре чираттагы чараларны үткәрә:

– алга таба лаборатор анализлау һәм анализ нәтиҗәләрен беркетмәләр рәвешендә тәкъдим итү өчен тикшерү объектларыннан (һава) пробалар ала;

– пробаларны алганда кирәкле үлчәмнәрне ясый;

– пробалар алыну турында акт формалаштыра.

Тикшерү объектларыннан пробалар алу буенча чараларны җаваплы башкаручы координацияли.

Үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планлы тикшерү үткәрүнең гомуми вакыты – егерме эш көненнән дә артык түгел.

5.2.4. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентының 1 нче кушымтасында китерелгән рәвештә тикшерү актын төзү әлеге Регламентның 5.1.7 пунктында күрсәтелгән тәртиптә башкарыла.

Тикшерү актына түбәндәгеләр теркәлергә мөмкин:

– продукция үрнәкләрен, атмосфера һавасын тикшерү пробаларын һәм җитештерү өлкәсе объектларын тикшерү пробаларын алу беркетмәләре;

– үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар һәм экспертизаларның беркетмәләре яисә бәяләмәләре;

– тикшерү нәтиҗәләренә бәйле булган башка документлар, яисә аларның күчермәләре.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентының 1 нче кушымтасында китерелгән рәвештә тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшерүләр, сынаулар, махсус эзләнүләр, экспертизаларның нәтиҗәләре буенча бәяләмә алу кирәк булган очракта, тикшерү акты контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң өч эш көненнән артмаган чорда юридик затка, шәхси эшмәкәргә юллана.

Җаваплы зат үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының исеме, үткәрелгән

тикшерүнең башлану һәм тәмамлану көннәре, аны үткәрүнең вакыты, хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм тикшерүнең предметы, ачыкланган хокук бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турындагы мәгълүматларны үз эченә алган язу терки, һәм шулай ук тикшерүне үткәрүче вазифаи затның яисә вазифаи затларның фамилияләрен, исемнәрен, аталарының исемнәрен һәм аның яисә аларның имзаларын, вазифаларын күрсәтә.

5.2.5. Үзен-үзе җайга салучы оешма әгъзаларының мәҗбүри таләпләрне бозулары ачыкланган очракта җаваплы башкаручы үзен-үзе җайга салучы оешмага ачыкланган бозулар турында үткәрелгән тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә белдерүнамә җибәрә.

5.2.6. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе ТР ЭТРМ рәсми сайтында электрон формада теркәлә.

### 5.3. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.3.1. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата плансыз документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлау өчен әлеге Регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

“Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасы түбәндәге эш тәртипләре буенча башкарыла:

планнан тыш документар тикшерүне үткәрү буенча җаваплы вазифаи затларны билгеләү турында карар кабул итү;

планнан тыш документар тикшерүнең үткәрелүе турында әмернамә формалаштыру;

планнан тыш документар тикшерүне үткәрү;

үткәрелгән планнан тыш документар тикшерүнең нәтиҗәләрен формалаштыру.

5.3.2. Министр (министр урынбасары), плансыз тикшерүне үткәрүгә әлеге Регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр килеп туганда, ТР ЭТРМ тиешле структур бүлекчәсенең башлыгына планнан тыш документар тикшерүне оештыру һәм үткәрү буенча йөкләмә бирә.

ТР ЭТРМның тиешле структур бүлекчәсе башлыгы:

юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата тикшерү үткәрү буенча җаваплы башкаручыны билгели;

кирәк булган очракта тикшерелүче юридик зат, шәхси эшмәкәр белән граждан-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелүче затларның аффилир затлары булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итә.

Үтәү вакыты: планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен нигез барлыкка килгән көннән алып бер эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш тикшерү үткәрү өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы.

5.3.3. Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы министр (министр урынбасары) боерыгын (әмернамәсен) әзерләү әлеге Регламентның 5.1.3 пункты нигезендә юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш документар тикшерү үткәрүгә җаваплы затны билгеләү көнендә башкарыла.

Үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш документар тикшерү үткәрүгә җаваплы затны билгеләү көнендә.

Эшнең нәтиҗәсе: тикшерүне үткәрү турында министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган боерык (әмернамә).

5.3.4. Җаваплы затның юридик затның, шәхси эшмәкәрнең документларында булган мәгълүматларны бәяләү, юридик зат, шәхси эшмәкәр адресына хат (нигезле гарызнамә) әзерләү, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең тапшырылган документларындагы кисәтүләр буенча аңлатмаларын карау буенча эш-гамәлләре әлеге Регламентның 5.1.5-5.1.6 пунктлары нигезендә башкарыла.

5.3.5. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентының 1 нче кушымтасында китерелгән рәвештә тикшерү актын төзү, юридик затны, шәхси эшмәкәрне тикшерү акты (аларны формалаштырганда кирәк булганда кушымталары белән берлектә) белән таныштыру әлеге Регламентның 5.1.7 пунктында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Элегрәк ачыкланган закон бозулар буенча бирелгән күрсәтмәләрнең үтәлешен тикшергәндә, ТР ЭТРМ законлы күрсәтмәсенең вакытында үтәлмәве, шулай ук РФ КоАП 19.5, 19.6 статьяларында каралган административ хокук бозуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрелмәү административ хокук бозулар буенча эш кузгатуга нигез булып тора.

Яңадан ачыкланган бозулар, шулай ук системалы характер алган бозу очраклары мәҗбүри тәртиптә теркәлә.

5.3.6. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе ТР ЭТРМ рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

### 5.4. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.4.1. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлау өчен әлеге Регламентның 2.4.2 пунктында каралган нигезләр, шулай ук документар тикшерү барышында түбәндәгеләр мөмкин булмаган очраклар нигез булып тора:

1) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең ТР ЭТРМ карамагына тапшырылган документларындагы мәгълүматларның тулылыгына һәм дөреслегенә ышану;

2) юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры

килүен контрольдә тоту буенча тиешле чараларны үткәрмичә бәяләп булмау.

5.4.2. Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү өчен җаваплы затны билгеләү, экспертларны җәлеп итү әлеге Регламентның 5.1.2 пункты нигезендә башкарыла.

5.4.3 Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турында боерык (әмернамә) әзерләү әлеге Регламентның 5.1.3 пункты нигезендә башкарыла.

5.4.4. Урынга чыгып планнан тыш тикшерүне үткәрүгә әлеге Регламентның 2.4.2 пунктының 2 пунктчасындагы “а”, “б” пункт өлешләрендә күрсәтелгән нигезләр нигез булып торса, җаваплы башкаручы:

юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата үткәреләчәк урынга чыгып планнан тыш тикшерүнең юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеге урыны буенча прокуратура органнары белән килештерү турында гариза әзерли һәм аны министрдан (министр урынбасарыннан) имзалата;

юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата үткәреләчәк урынга чыгып планнан тыш тикшерүнең юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эш урыны буенча прокуратура органнары белән килештерү турында гаризаны атап тапшыра, почта аша заказлы хат итеп кулга тапшыру белдерүнамәсе белән яисә электрон сан имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә юллый.

Гаризага министрның (министр урынбасарының) урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы боерыгының (әмернамәсенең) күчермәсе һәм аны үткәрүгә нигез булган, мәгълүматларны үз эченә алучы документлар теркәлә.

Үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы боерык (әмернамә) имзаланган көнне.

Эшнең нәтиҗәсе: урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрүне килештерү турында прокуратура органына юлланган гариза.

Урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү өчен гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә зыян салыну, һәм шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу, мондый бозуларны ачыклаган моментта мәҗбүри таләпләрнең бозылуын ачыклау нигез булып торганда, кичекмәстән чаралар күрү кирәклеге сәбәпле, ТР ЭТРМ, урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турында гаризаны, урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы әмернамәнең һәм аны үткәрүгә нигез булучы мәгълүматларны үз эченә алучы документларның күчермәләрен егерме дүрт сәгать эчендә юллау юлы белән, прокуратура органнарына хәбәр итеп, кичекмәстән урынга чыгып планнан тыш тикшерүне үткәрүгә керешергә хокуклы. Мондый очракта прокурор яисә аның урынбасары урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрүне килештерү турындагы карарны тиешле документлар кергән көнне кабул итә.

5.4.5. Җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшмәкәргә (әлеге Регламентның 2.4.2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә үткәрелүче урынга чыгып планнан тыш тикшерүдән гайре) карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турында аны үткәрә башлаганчы егерме дүрт сәгать алдан теләсә нинди үтемле ысул белән хәбәр итә.

Әгәр дә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә зыян салынган булса яисә салынса, һәм шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкса яисә килеп чыгарга мөмкин булса, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрүнең башлануы турында алдан хәбәр итү таләп ителми.

Үзен-үзе җайга салучы оешма әгъзаларына карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәргәндә, җаваплы башкаручы, урынга чыгып

үткәрелгән планнан тыш тикшерүдә аның вәкилләрен катнаштыру һәм булдыруны тәэмин итү максатларында, урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турында үзен-үзе җайга салучы оешмага хәбәр итә.

5.4.6. Урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү әлеге Регламентның 5.2.3 пункты нигезендә башкарыла.

Элегрәк ачыкланган закон бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрнең үтәлешен тикшергәндә ТР ЭТРМ тарафыннан бирелгән законлы күрсәтмәнең билгеләнгән вакытка үтәлмәве, шулай ук РФ КоАП 19.5, 19.6 статьяларында каралган административ хокук бозуларга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чараларның күрелмәве административ хокук бозулар буенча эш кузгатуга нигез булып тора.

Яңадан ачыкланган бозулар, шулай ук системалы характерга ия булган бозу очраклары мәҗбүри тәртиптә теркәлә.

5.4.7. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентының 1 нче кушымтасында китерелгән рәвештә тикшерү актын төзү әлеге Регламентның 5.2.4 пункты нигезендә башкарыла.

Әгәр дә урынга чыгып үткәрелгән планнан тыш тикшерү прокуратура органы белән килештерелеп башкарылган булса, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентының 1 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә төзелгән тикшерү актының күчермәсе, тикшерү актын төзү көненнән алып биш эш көне дәвамында, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентының 1 нче кушымтасында китерелгән рәвештә прокуратура органына юллана.

5.4.8. Үзен-үзе җайга салучы оешма әгъзалары тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы ачыкланган

бозулар турында урынга чыгып үткәрелгән планнан тыш тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көне дәвамында үзен-үзе җайга салучы оешмага хәбәр итә.

5.4.9. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәүнең нәтиҗәсе ТР ЭТРМ рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

## 6. Дәүләт функциясен үтәүне контрольдә тотуның тәртибе һәм рәвешләре

6.1. ТР ЭТРМ вазифаи затлары тарафыннан аларның хезмәт йөкләмәләре үтәлүен контрольдә тота, тикшерүләрне үткәргәндә вазифаи затлар тарафыннан вәкаләтләренең тиешенчә үтәлмәве очракларының исәбен алып бара, тиешле хезмәт тикшеренүләрен алып бара һәм, Россия Федерациясе законнары нигезендә, мондый вазифаи затларга карата чаралар күрә.

6.2. Әлеге Регламентның үтәлешен контрольдә тоту министр тарафыннан башкарыла.

6.3. Әлеге Регламент нигезендә дәүләт күзәтчелеген башкару буенча эшләрнең вакытлары, эзлеклелеге үтәлешен, ТР ЭТРМ вазифаи затлары тарафыннан карарларның кабул ителүен агымдагы контрольдә тоту министрның урынбасары һәм ТР ЭТРМның вәкаләтле хезмәткәрләре тарафыннан башкарыла.

6.4. Дәүләт функциясе үтәлешен, әлеге контрольнең тәртибе һәм эзлеклелеге саклануны агымдагы контрольдә тотуга вәкаләт бирелгән ТР ЭТРМ хезмәткәрләренең исемлеге ТР ЭТРМ актлары белән билгеләнә. ТР ЭТРМ хезмәткәрләренең агымдагы контроль буенча вәкаләтләре ТР ЭТРМ структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә, хезмәткәрләрнең вазифаи күрсәтмәләрендә билгеләнә.

6.5. ТР ЭТРМ тарафыннан үтәлүче дәүләт функциясенең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүне,

тикшерелүче затларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерүне, кызыксынучы затларның ТР ЭТРМ вазифаи затларының гамәленә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләреннән торучы мөрәҗәгатьләрен карау, алар буенча карарлар кабул итү һәм аларга җавап әзерләүне үз эчен ала.

Тикшерүләр министрның (министр урынбасарының) әмернамәсе нигезендә үткәрелә. Тикшерүләрнең нәтиҗәләре дәүләт функциясен үтәгәндә кимчелекләрнең булмавы яисә ачыкланган кимчелекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр теркәлгән акт рәвешендә формалаштырыла.

6.6. Дәүләт функциясен үтәүнең тулылыгын һәм сыйфатын планлы тикшерүләр агымдагы елга билгеләнгән ТР ЭТРМ еллык эшләр планы нигезендә башкарыла. Планлы тикшерүләр әлеге планга дәүләт функциясен үтәү аның компетенциясенә караган министр урынбасары тарафыннан кертелә.

6.7. Дәүләт функциясен үтәүнең тулылыгына һәм сыйфатына карата үткәрелүче планнан тыш тикшерүләр ТР ЭТРМ вазифаи затларының дәүләт функциясен үтәү барышында кабул ителгән яисә башкарылган карарларына яисә гамәленә (гамәл кылмавына) карата гражданнардан алынган шикаятьләр (ризасызлыклар) нигезендә башкарыла.

6.8. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә дәүләт функциясен үтәү барышында Министрлыкның вазифаи затлары тарафыннан бозулар җибәрелгәнлеге ачыкланса, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла һәм ачыкланган бозуларны бетерү буенча чаралар күрелә.

6.9. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә иҗтимагый контроль (иҗтимагый экология контроле) уңайлы әйләнә-тирә мохиткә һәркемнең хокукларын гамәлгә ашыру һәм атмосфера һавасын саклау өлкәсендәге законнарның бозылуын булдырмый калу максатларында башкарыла.

Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә иҗтимагый контроль (иҗтимагый экология контроле) иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерцияле

булмаган башка оешмалар тарафыннан аларның уставлары нигезендә, шулай ук гражданнар тарафыннан законнарга нигезләнеп башкарыла.

6.10. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә иҗтимагый контрольнең (иҗтимагый экология контроленең) Россия Федерациясенең дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган нәтиҗәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри каралырга тиешле.

## 7. Дәүләт функциясен үтәүче органның, шулай ук анның вазифаи затларының карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауларын) судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылу тәртибе

7.1. Юридик затның җитәкчесе, башка вазифаи заты яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, анның вәкаләтле вәкиле, башка кызыксынучан затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) ТР ЭТРМ дәүләт функциясен үтәү барышында анның вазифаи затлары тарафыннан тикшерүне үткәрү барышында юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокукларын бозуга китергән гамәлләрен (гамәл кылмауларын) һәм кабул ителгән (кабул ителүче) карарларын, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылырга хокуклы.

7.2. ТР ЭТРМ, анның вазифаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылуның предметы булып ТР ЭТРМ вазифаи затларының, анның территориаль идарәләренең дәүләт функциясен үтәү барышында кабул иткән яисә башкарган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) тора.

7.3. Министрлыкка яисә вазифаи затка аларның компетенциясенә бәйле рәвештә кергән шикаять мәҗбүри каралырга тиешле. Судка кадәр (судтан тыш) каралырга тиешле шикаятьне караудан баш тартуга яисә карауны туктатып торуга нигезләр каралмаган.

7.4. Шикаятькә җавап түбәндәге очракларда бирелми:

– әгәр дә язмача шикаятьтә шикаять белән мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе), җавап җибәрү өчен почта адресы  күрсәтелмәсә (әгәр дә әлеге шикаятьтә әзерләнеп ятучы, башкарылучы яисә хокукка каршы хәлләрнең башкарылуы  турында, һәм шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яисә башкарган зат турында мәгълүматлар булса, шикаять компетенциясенә караган дәүләт органына юлланырга тиеш);

– шикаятьтә цензурасыз яисә мыскыллы тәгъбирләр кулланылса, ТР ЭТРМ вазифаи затының, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм милкенә куркыныч белән янаулар булса (ТР ЭТРМ вазифаи заты шикаять белән мөрәҗәгать итүчегә хокуклары белән исәпләшмәүнең мөмкин түгеллеге хакында хәбәр итәргә хокуклы);

– әгәр дә язмача шикаятьнең тексты укылышлы булмаса (әлеге шикаять шулай ук аларның компетенциясе кысаларында дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә вазифаи зат каравына җибәрелми), бу хакта шикаятьне теркәгән көннән җиде көн дәвамында шикаять белән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр дә аның фамилиясе (юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе), почта адресы аңлаешлы булса;

– әгәр дә мөрәҗәгать итүченең шикаятендә аңа инде элегрәк җибәрелгән шикаятьләре нигезендә күп тапкыр язмача җавап бирелгән сорау каралса һәм, шул ук вакытта, шикаятьтә яңа дәлилләр һәм шартлар китерелмәсә (әлеге шикаять һәм элегрәк җибәрелгән шикаятьләр бер үк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә шул ук вазифаи затка җибәрелгән очракта (шикаять белән мөрәҗәгать итүчегә ике арадагы язышуларны туктату карары турында хәбәр ителә);

– әгәр дә шикаятьтә куелган сорауга дәүләт яисә федераль закон белән саклanучы башка серне тәшкил иткән мәгълүматларны фаш итүдән гайре җавап биреп булмаса (шикаять белән мөрәҗәгать итүчегә, әлеге мәгълүматларны фаш итү мөмкин булмау сәбәпле, анда куелган сорауга җавап биреп булмау мөмкинлеге турында хәбәр ителә).

Суд карарына карата шикаять, теркәлү узганнан соң җиде көн эчендә, әлеге суд карарын шикаять кылу тәртибе аңлатылып, мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарыла.

7.5. Мөрәҗәгать итүченең шәхсән үзеннән (мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле вәкиленнән) яисә почта аша җибәрелгән хат, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән, шул исәптән Министрлыкның рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә ТР ЭТРМ кергән шикаять ТР ЭТРМ, аның вазифаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылуны башлауга нигез булып тора.

7.6. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр шикаятьне дәлилләү һәм карау өчен кирәкле булган мәгълүматларны һәм документларны алуга хокуклы. Мондый төр мәгълүматларны һәм документларны алу өчен юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр ТР ЭТРМ адресына язмача рәвештә тиешле гарызнамә юлларга тиеш. Министр (министр урынбасары), җаваплы башкаручылар соралучы мәгълүматларны һәм документларны гаризаны теркәгән көннән 30 көн эчендә бирергә тиеш.

7.7. ТР ЭТРМ вазифаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять министрга юлланырга мөмкин. ТР ЭТРМ һәм министрның гамәлләренә (гамәл кылмауларына), карарларына карата шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланырга мөмкин.

7.8. ТР ЭТРМ яисә ТР ЭТРМ вазифаи затына кергән шикаять, аларның компетенциясе нигезендә, аның теркәлү көненнән 30 календарь көне дәвамында карала.

Искәрмәле очракларда, вазифаи яисә аңа вәкаләтле булган зат шикаятьне карау вакытын, шикаять белән мөрәҗәгать итүчегә аның карау вакытын озынайту турында хәбәр итеп, 30 календарь көненнән артмаган вакытка озынайта ала.

7.9. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылуның нәтиҗәләре

түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) дәүләт функциясен үтәү барышындагы гамәлләргә (гамәл кылмауларына) һәм кабул ителгән карарларга карата бирелгән судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндерү, ә атап әйткәндә:

– хезмәт тикшерүе барышында җаваплы башкаручының (җаваплы башкаручыларның) вазифаи йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәү очраклары ачыкланган очракта, аңа карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрү;

– хокуклары һәм (яисә) законлы ихтыяҗлары бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозуда гаеплеләргә карата күрелгән чаралар турында, мондый чараларны күрү көненнән ун көн дәвамында язмача рәвештә хәбәр итеяә.

2) юридик затка, шәхси эшмәкәргә мондый карарның нигезләрен күрсәтеп, язмача хәбәр итү юлы белән, дәүләт функциясен үтәү барышындагы гамәлләргә (гамәл кылмауларга) һәм кабул ителгән (кабул ителүче) карарларга карата судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндермәү.

7.10. ТР ЭТРМ кергән шикаятькә җавап мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентның 7.9 п. каралган чараларны күргән көннән 10 көн дәвамында җибәрелә.

ТР ЭТРМ яисә вазифаи затка электрон документ рәвешендә кергән шикаятькә җавап электрон документ рәвешендә, шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресы  яисә шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы аша язмача җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый ресурслар
министрлыгының атмосфера һавасын
саклау, шул исәптән атмосфера һавасына
пычраткыч матдә һәм башка матдә
ташландыклары өчен түләүне
контрольдә тоту өлкәсендә
төбәкара дәүләт күзәтчелеген
гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен үтәүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

**Административ хокук бозу турында беркетмә**
**(юридик затка карата)**
**(рәвеше)**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ**
**ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

_______________________________________________________________________________

№ __________________
(теркәү кенәгәсе буенча)

**Административ хокук бозу турында**
**№_________ БЕРКЕТМӘ**

«____»_____________201___ел.

___________________________ ___________________
(беркетмәне төзү көне) (беркетмәне төзү урыны)

Мин, ТР табигатьне саклау буенча дәүләт инспекторы _______________________________________
_______________________________________________________________________________
(беркетмә төзүче затның вазифасы, фамилиясе һәм инициаллары)

“Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” 10.01.2002, № 7-ФЗ Федераль законның 6.66 ст., 30.12.2001 ел, № 195-ФЗ Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының (алга таба – КоАП РФ) 28.2, 28.3 ст., 1 ө. нигезләнеп, түбәндәгегә карата беркетмә төзедем

_______________________________________________________________________________
(юридик затның оештыру-хокукый рәвеше, исеме)
_______________________________________________________________________________
(юридик адресы, телефоны)
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

Төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) | | | | | | | | | | | | | | |

Юридик затның реквизитлары ИНН/КПП | | | | | | | | | | | / | | | | | | | | | |

р/с | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | ______________________
(банк исеме)

кор/с | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

БИК | | | | | | | | | | ОКПО | | | | | | | | ОКВЭД | | | | | ОКОНХ | | | | | |

түбәндәгеләр катнашында _________________________________________________________
(юридик затның законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ,
_______________________________________________________________________________,
фамилиясе, исеме, атасының исеме)

түбәндәгеләргә хилафлык китерүче административ хокук бозылган______________________
_______________________________________________________________________________
(әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге федераль законнарның, нормативларның, норматив документларның тулы исемлеге күрсәтелә)
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

Аның өчен КоАП РФ ____ ст. буенча җаваплылык каралган, ә атап әйткәндә:
«__»___________201___ел. __сәг.__минутта ______________________ тор. пунктында
биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан файдаланганда түбәндәгеләрне бозды:_______

_______________________________________________________________________________________________
(хокук бозу вакыйгасы, табигатьне саклау законнарының бозылган таләпләре,
_______________________________________________________________________________________________
мәйданы, күләме)
_______________________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________________

Әлеге беркетмә административ хокук бозу турында эш башкарылучы зат ______________________ (юридик затның законлы вәкиленең Ф.И.А.) катнашында төзелде, аңа аның РФ КоАП 25.1, 25.4 статьялары белән каралган хокуклары һәм бурычлары турында аңлатылды. Рус телен беләм, тәрҗемәчегә мохтаҗ түгел. (Административ җаваплылыкка тартылучы зат эшнең материаллары белән танышырга, аңлатмалар бирергә, дәлилләр китерергә, үтенеч язуларын тапшырырга һәм кире кагарга; беркетмәне төзүгә вәкаләтле затның процессуаль эшләрен шикаять кылырга; эшне карау барышында яклаучының юридик ярдәменнән һәм шулай ук, әлеге Кодекс нигезендә, башка процессуаль хокуклардан файдаланырга хокуклы).

**Таныштым:**_____________________________________________________________
(юридик затның законлы вәкиленең имзасы, имзаның тәгъбирләнеше)
Юридик затның законлы вәкиленең аңлатмасы һәм кисәтүләре:_____________________________
_______________________________________________________________________________________________
(беркетмәнең эчтәлеге буенча кирәк булганда аңлатмалар һәм кисәтүләр аңа аерым биттә теркәлә)
_______________________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________________

_____________________________________________________
(юридик затның законлы вәкиленең имзасы, имзаның тәгъбирләнеше)
Шаһитлар: 1. (Ф.И.А.)_____________________________________________________________________
(яшәү урыны буенча адресы, телефон)
_______________________________________________________________________________________________
2. (Ф.И.А.)_______________________________________________________________________________
(яшәү урыны буенча адресы, телефон)
_______________________________________________________________________________________________

РФ КоАП 25.6 статьясында каралган хокукларым һәм бурычларым турында миңа аңлатылды:
1.______________________ , 2.______________________
(имза, имзаның тәгъбирләнеше) (имза, имзаның тәгъбирләнеше)

Беркетмәгә түбәндәгеләр теркәлә:_____________________________________________________
(беркетмәгә теркәлүче документларны күрсәтергә)
_______________________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________________

**Сез түбәндәге адрес буенча:______________, _______________ур.___й. ____каб.____ сәг.____минутта, 201__елның «____»__________административ хокук бозуны карау өчен чакырыласыз.**

**Чакырылучының имзасы:**_________________________________________________________
(юридик затның законлы вәкиленең имзасы, имзаның тәгъбирләнеше)
Беркетмәне төзүче затның имзасы: __________________________________________________
(имза, имзаның тәгъбирләнеше)
Беркетмәнең күчермәсен алдым:______________________________________________________
(административ хокук бозу буенча эш башкару алып барылучы юридик затның законлы вәкиленең имзасы, имзаның тәгъбирләнеше)

«______»_______________ 201___ел.

**Административ хокук бозу турында беркетмә**
**(вазифаи затка карата)**
**(рәвеше)**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

_______________________________________________________________________________________________
№ __________________
(теркәү кенәгәсе буенча)

**Административ хокук бозу турында**
**№_________БЕРКЕТМӘ**

«____»______________201___ел.

________________________ ____________________

(беркетмәне төзү көне) (беркетмәне төзү урыны)

Мин, ТР табигатьне саклау буенча дәүләт инспекторы ____________________________________

_______________________________________________________________________________________________

(беркетмә төзүче затның вазифасы, фамилиясе һәм инициаллары)

“Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” 10.01.2002, № 7-ФЗ Федераль законның 6.66 ст., 30.12.2001 ел, № 195-ФЗ Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының (алга таба – КоАП РФ) 28.2, 28.3 ст., 1 ө. нигезләнеп, түбәндәгегә карата беркетмә төзедем

_________________________________________________________________________________________ _____

(физик, вазифаи, юридик зат булып оешмаган эшмәкәр (ПБОЮЛ)

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

Фамилиясе исеме атасының исеме

1.Туган көне һәм урыны

_______________________________________________________________________________________________

2.Эш урыны, вазифасы

_______________________________________________________________________________________________

(предприятиенең, учреждениенең исеме, адресы, билгеләү турында боерык)

3.Яшәү урыны һәм телефоны ____________________________________________________

4.Шәхси эшмәкәр өчен: ИНН ____________________________________________________

5.Теркәлү урыны һәм телефоны __________________________________________________

6.Шәхесен таныклаучы документы_______________________________________________________

(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

түбәндәгеләргә хилафлык китерүче административ хокук бозылган _______________________

_______________________________________________________________________________________________

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге федераль законнарның, нормативларның, норматив документларның тулы исемлегә күрсәтелә)

_______________________________________________________________________________________________

Аның өчен РФ КоАП _____ ст. буенча җаваплылык каралган, ә атап әйткәндә:

«__»___________201___ел. __сәг.__минутта _______________________ тор. пунктында

түбәндәге биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан файдаланганда:____________________

(вазифаи затлар өчен)

_______________________________________________________________________________________________

(юридик затның исеме, урнашу урыны)

Шушы адрес буенча: ____________________________________________________________

(физик затлар өчен) (административ хокук бозуга юл куелган урынның адресы)

түбәндәгеләрне бозды: _____________________________________________________________________

(хокук бозу вакыйгасы, табигатьне саклау законнарының бозылган таләпләре, мәйданы, күләме)

_______________________________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________________________

Әлеге беркетмә административ хокук бозу турында эш башкарылучы зат _______________________ (юридик затның законлы вәкиленең Ф.И. А.) катнашында төзелде, аңа аның РФ КоАП 25.1, 25.3 статьялары белән каралган хокуклары һәм бурычлары турында аңлатылды. Рус телен беләм, тәрҗемәчегә мохтаҗ түгел. (Административ җаваплылыкка тартылучы зат эшнең материаллары белән танышырга, аңлатмалар бирергә, дәлилләр китерергә, үтенеч язуларын тапшырырга һәм кире кагарга; беркетмәне төзүгә вәкаләтле затның процессуаль эшләрен шикаять кылырга; эшне карау барышында яклаучының юридик ярдәменнән һәм шулай ук, әлеге Кодекс нигезендә, башка процессуаль хокуклардан файдаланырга хокуклы).

**Таныштым:**_____________________________________________________________

(юридик затның законлы вәкиленең имзасы, имзаның тәгъбирләнеше)

Административ хокук бозу турында эш башкарылучы затның (физик затның законлы вәкиленең) аңлатмасы______________________________________________________________________

______________________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________________

____________________________
(имза, имзаның тәгъбирләнеше)

Шаһитлар:1.(Ф.И.А)_____________________________________________________________

______________________________________________________________________________________
(яшәү урыны буенча адресы)

2.(Ф.И.А.)_________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________________
(яшәү урыны буенча адресы)

РФ КоАП 25.6 статьясында каралган хокукларым һәм бурычларым турында миңа аңлатылды:
1.______________________, 2.________________________
(имза, имзаның тәгъбирләнеше) (имза, имзаның тәгъбирләнеше)

Беркетмәгә түбәндәгеләр теркәлә:___________________________________________________
(беркетмәгә теркәлүче документларны күрсәтергә)

______________________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________________

**Сез түбәндәге адрес буенча:_______________, ________________ур.___й. ____каб.____ сәг.____минутта, 201__елның «____»___________административ хокук бозуны карау өчен чакырыласыз.**

**Чакырылучының имзасы:___________________________________________________**
(юридик затның законлы вәкиленең имзасы, имзаның тәгъбирләнеше)

Беркетмәне төзүче затның имзасы: _______________________________________________
(имза, имзаның тәгъбирләнеше)

Беркетмәнең күчермәсен алдым: __________________________________________________
(Административ хокук бозу турында эш башкарылучы затның имзасы, имзаның тәгъбирләнеше)

«______»______________201____ел.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый ресурслар
министрлыгының атмосфера һавасын
саклау, шул исәптән атмосфера һавасына
пычраткыч матдә һәм башка матдә
ташландыклары өчен түләүне
контрольдә тоту өлкәсендә
төбәкара дәүләт күзәтчелеген
гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен үтәүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

**Ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә**
**(рәвеше)**

| | | |
|---|---|---|
| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАР МИНИСТРЛЫГЫ | Герб Республики Татарстан | МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН |

(дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының яисә аның территориаль органының исеме)

___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
Почта адресы: (дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы).; тел. (Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы).

________________________ «__» ________ 20__ ел.
(Актны төзү урыны) (актны төзү көне)

______________________
(актны төзү вакыты)

ТИКШЕРҮЛӘР НӘТИҖӘСЕНДӘ АЧЫКЛАНГАН
ТАБИГАТЬНЕ САКЛАУ ЗАКОННАРЫН БОЗУЛАРНЫ БЕТЕРҮ ТУРЫНДА
№ _____ КҮРСӘТМӘ

«__» ________ 20 ел. __________________ ш.

Россия Федерациясенең табигатьне саклау законнарының таләпләрен үтәүне тикшерү буенча 20__ елның «__» ________. № ___ актына нигезләнеп, мин, ТР табигатьне саклау буенча дәүләт инспекторы

___________________________________________________________________________
(ТР ЭТРМ яисә аның территориаль органының вазифаи затының Ф.И.А.,

___________________________________________________________________________
вазифасы, хезмәт таныклыгы номеры,кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

КҮРСӘТМӘ БИРӘМ

___________________________________________________________________________
(күрсәтмә бирелүче физик яисә юридик затның исеме)

| № п/п | Табигатьне саклау законнарының ачыкланган бозулары <**> | Ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәнең эчтәлеге <*> | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Күрсәтмә законда каралган тәртиптә шикаять кылынырга мөмкин. Шикаять кылу әлеге күрсәтмәнең үтәлешен туктатмый.

--------------------------------

<*> Тикшерелүче зат башкарырга тиешле конкрет чаралар күрсәтелә.

<**> Күрсәтмәләнүче бурычларны караган норматив-хокукый актка сылтамалар күрсәтелә.

Вазифаи затның вазифасы:


____________________________________ _____________ __________________
(Ф.И.А.) (имзасы) (дата)


Күрсәтмә алынды

___________________________________ ___________________________________
(шәхси эшмәкәрнең яисә тикшерелүче оешма җитәкчесенең (вәкаләтле вәкиленең)Ф.И.А.) шәхси эшмәкәрнең яисә тикшерелүче оешма җитәкчесенең (вәкаләтле вәкиленең)имзасы)

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый ресурслар
министрлыгының атмосфера һавасын
саклау, шул исәптән атмосфера һавасына
пычраткыч матдә һәм башка матдә
ташландыклары өчен түләүне
контрольдә тоту өлкәсендә
төбәкара дәүләт күзәтчелеген
гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен үтәүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮНЕҢ БЛОК-СХЕМАСЫ




Урынга чыгып тикшерү турында карар кабул итү
Атмосфера һавасын саклау һәм атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка матдә ташландыклары өчен түләү өлкәсендә законнарны бозу очракларының булмавын ачыклау
Атмосфера һавасын саклау һәм атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка матдә ташландыклары өчен түләү өлкәсендә законнарны бозу очракларын ачыклау
Тикшерүне тәмамлау көнендә ике нөсхәдә тикшерү акты төзү
Административ хокук бозу турында эш ачу
Ачыкланган хокук бозулар турында күрсәтмәләр төзү һәм бирү
Компетенцияләре кысаларында мәгълүматларны дәүләт органнарына юллау
РФ КоАП нигезендә административ башкару эше
Атмосфера һавасын саклау һәм атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка матдә ташландыклары өчен түләү өлкәсендә законнарны бозуларны бетерүне күзәтү
Юридик затның җитәкчесен, шәхси эшмәкәрне (аларның вәкилләрен) акт (ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә) белән таныштыру
Юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү актын кушымталарының күчермәләре белән берлектә тапшыру яисә почта аша кулына тапшыру хәбәрнамәсе белән юллау
Тикшерү акты күчермәсен прокуратура органына юллау (прокуратура органы белән килештерелгәндә)
Җаваплы башкаручы тарафыннан урынга чыгып үткәрелгән тикшерүне тикшерүләрне исәпкә алу журналына теркәү
Тикшерү акты күчермәсен прокуратура органына юллау (прокуратура органы белән килештерү булган очракта)

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый ресурслар
министрлыгының атмосфера һавасын
саклау, шул исәптән атмосфера һавасына
пычраткыч матдә һәм башка матдә
ташландыклары өчен түләүне
контрольдә тоту өлкәсендә
төбәкара дәүләт күзәтчелеген
гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен үтәүнең
административ регламентына
4 нче кушымта
(Типик рәвеше)

Юридик зат (шәхси эшмәкәр) объектында (объектларында)
контрольлек итү буенча чаралар үткәрүнең
җаваплы башкаручылар, АКМИ белгечләре өчен
ПЛАН-БИРЕМЕ

ТР табигатьне саклау буенча баш дәүләт инспекторының (ТР табигатьне саклау буенча Баш дәүләт инспекторы урынбасарының) юридик зат (шәхси эшмәкәр) объектында (объектларында) контрольлек итү буенча чаралар үткәрү турында
елның ___________ (дата)
№________ боерыгы (әмернамәсе) нигезендә

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________:
(юридик затның тулы һәм (булган очракта) кыскартылган исеме, шул исәптән фирма исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, Исеме һәм (булган очракта) атасының исеме)

1. Тикшерүне үткәрүгә вәкаләтләнгән хезмәткәрләргә әлеге объектта (объектларда) чираттагы чараларны үткәрергә:

| Контроль буенча чара | Үтәү вакыты | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

2. Тикшерүне үткәрүгә вәкаләтләнгән аналитика контрольлегенең махсуслашкан инспекциясе белгечләренә объектта (объектларда) чираттагы чараларны үткәрергә:

| Контроль буенча чара | Үтәү вакыты | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

________________________________________ ____________________
(Баш җаваплы башкаручының ФИА, имзасы) (дата)